ФГОС

Школьный учебник
«Татарский язык»

КҮҢЕЛЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ

Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



## 4 класс

ИКЕНЧЕ КИСӘК

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»





Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ)

ДӘРЕСЛЕК Е.И.ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ

Ике кисәктә

2 НЧЕ КИСӘК

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2014

Р.З.Хайдарова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## ЧЕТВЁРТЫЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
НАЧАЛЬНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(НА РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ
Е.И.ПАССОВА

В двух частях

ЧАСТЬ 2

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2014

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3-2я722
Х18

Линейка учебников «Татар теле» («Татарский язык») (1-4 классы) Р.З.Хайдаровой, Н.Г.Галиевой, Г.М.Ахметзяновой, Л.А.Гиниятуллиной издательства «Татармультфильм» входит в **Федеральный перечень учебников**, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образования.

Учебники включены в Федеральный перечень на основании Экспертных заключений:

– Российской академии наук №№001330-001333 от 15.01.2014 г. (педагогическая экспертиза учебников),

– Российской академии наук №10106-5215/283 от 15.10.2013 г. (научная экспертиза учебников),

– НП «Российский книжный союз» от 10.02.2014 г. (общественная экспертиза учебников),

– Министерства образования и науки Республики Татарстан №1865/14–30–33 от 10.02.2014 г. (этнокультурная и региональная экспертиза учебников).

## Условные обозначения

 — начало урока

— запомни

— вспомни

 — обрати внимание

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования, в 2-х частях (на русском и татарском языках). / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А Гиниятуллина. — Казань : Татармультфильм, 2014. — 128 с.: ил. — (Татар теле). — ISBN 978-5-906508-02-7.

**ISBN 978-5-906508-02-7**

**УДК 811.512.145(07)**
**ББК 81.632.3я72**

© Издательство «Татармультфильм», 2014
© Художественное оформление Издательство «Татармультфильм», 2014
Все права защищены



ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»

# МИНЕМ ДУСЛАРЫМ

## 91—92 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен тап.

| | |
|---|---|
| **дус** | **мой друг, моя подруга** |
| **дустым** | **друг, подруга** |
| **дуслаштык** | **подружились** |
| **бергә** | **вместе** |

**2.** Төрләнешне дәвам ит.

Минем дустым.
Синең ... .
Аның ... .
Безнең ... .
Сезнең ... .
Аларның ... .

**3.** Рәсемгә кара һәм әйт: балалар дуслармы? Алар нишлиләр?



**4**. Диалогны укы һәм партадашың белән сөйләш.

— Айрат, Петя белән Шамил дуслармы?
— Әлбәттә, дуслар. Алар гел бергә уйныйлар.
— Айрат, әйдә без дә чаңгы шуабыз.
— Кайчан чыгабыз?
— Дәрестән соң.

**5.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә, дустың белән сөйләш.

а) — ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— Аның исеме ничек?
— ... .
— ... ?
— Ул дүртенче сыйныфта укый.

ә) — Әйт әле, Надя, син Оля белән дусмы?
— Әйе, без бик дус.
— ... ?
— Авылда.
— ... ?
— Кышкы каникулда.

**6.** Синең дустың бармы? Дустың турында сөйләргә өйрән. Сиңа таблица ярдәм итәр.

| Сөйләү планы | Терәк сүзләр, сүзтезмәләр |
|---|---|
| 1. Без кайда дуслаштык? | авылда, шәһәрдә, ишегалдында, түгәрәктә, лагерьда, мәктәптә |
| 2. Дустым кайда яши? | ... шәһәрдә, ... авылда |
| 3. Дустым кайда укый? | ... мәктәптә, ... сыйныфта |

**7.** Спроси у друга:

— идёт ли он сегодня кататься на лыжах;
— готовил ли он вчера домашнее задание;
— есть ли у него друзья;
— с кем он поиграет вечером.

**8.** Диалогларны укы. Ошаган диалогны дустың белән сөйләш.



1. — Алло, хәерле көн!
— Хәерле көн!
— Наташа, әйдә чаңгы шуарга барабыз.
— Юк әле, Лена, бармыйм.
— Нигә?
— Безнең иртәгә математикадан контроль эш. Мин дәрес әзерлим.



2. — Алло, хәерле көн! Мин — Лена. Айгөл кирәк иде.
— Хәзер чакырам!
— Айгөл, исәнме! Син математикадан өй эшен әзерләдеңме?
— Юк әле, Лена, әзерләмәдем.
— Әйдә бергә әзерлибез.
— Ярый, кил, мин сине көтәм.

## 93—94 нче дәресләр

**1.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит. Бирелгән саннар белән 3—4 җөмлә уйла.

**ике — два**

**өч — ...**

**дүрт — ...**

**икебез — вдвоём**

**өчебез — ...**

**дүртебез — ...**

**икенче — второй**

**өченче — ...**

**дүртенче — ...**

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

[дусты́м], [а°wы̆лға́], [күршә̆лә́р], [бийү́ түгәрәгә́], [туры̆нда́], [йа°лқа́у], [за°ма́нча], [пә̆шә̆рә́], [өйрәтә́].

**3.** Сүзләрнең антоним парларын тап, җөмләләр төзе.

| | | |
|---|---|---|
| эшчән | | куркак |
| яхшы | **?** | ялкау |
| батыр | | саран |
| юмарт | | начар |

**4.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит.

кружок математики — математика түгәрәге
ходит на кружок математики — математика түгәрәгенә йөри
кружок татарского языка — ...
ходит на кружок татарского языка — ...
кружок английского языка — ...
ходит на кружок английского языка — ...
спортивный кружок — ...
ходит на спортивный кружок — ...
танцевальный кружок — ...
ходит на танцевальный кружок — ...

**5.** Хикәяне укы.

### Минем дустым

Минем исемем — Айсылу. Мин сезгә дустым турында сөйлим. Аның исеме — Айгөл. Без аның белән авылда җәйге каникулда дуслаштык. Айгөл дә, мин дә Казанда яшибез, бер йортта торабыз, бер мәктәптә укыйбыз. Мин — дүртенче, ә ул бишенче сыйныфта укый.



Без бик дуслар. Без бергә бию түгәрәгенә йөрибез. Татар, рус, молдаван биюләре дә, заманча биюләр дә өйрәнәбез.

Дәрестән соң без бергә чаңгы шуабыз, бергә дәрес әзерлибез.

Айгөл — яхшы укучы, «4»ле, «5»ле билгеләре ала. Ул бик эшчән дә. Өйдә ашарга пешерә, өй җыештыра.

**бер өйдә** — в одном доме
**бию түгәрәге** — танцевальный кружок
**заманча** — современный

**6.** Хикәядән сорауларга җавап (ответы на вопросы) булган җөмләләрне табып укы.

1. Кызлар кайда дуслашты?
2. Кызлар кайда яши?
3. Кызлар бергә нишлиләр?

**7.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1. Без аның белән авылда җәйге каникулда дуслаштык. 2. Без бергә чаңгы шуабыз, бергә дәрес әзерлибез. 3. Без бергә бию түгәрәгенә йөрибез. 4. Без бик дуслар. 5. Мин сезгә дустым турында сөйлим. 6. Аның исеме — Айгөл.

**8.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Без Айгөл белән шәһәрдә дуслаштык.
   Без Айгөл белән авылда дуслаштык.

2. Мин җәйге каникулда авылга кайттым.
Без Айгөл белән җәйге каникулда лагерьда ял иттек.

3. Без заманча биюләр өйрәнәбез.
Без заманча биюләр өйрәнмибез.

4. Айгөл — биюче, ләкин ул яхшы укымый.
Айгөл — яхшы укучы да, оста биюче дә.

**9.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп яз.

1. Мин... исем... — Айсылу. 2. Мин сез... дуст... Айгөл турында сөйләргә телим. 3. Ул — дүрт... сыйныф... , мин биш... сыйныф... укыйм. 4. Без бию түгәрәгенә йөрибез.

**10.** Текстны сәнгатьле укырга өйрән.

## 95—96 нчы дәресләр

**1.** Сәнгатьле укучыга конкурс! Укыганда бәя бирергә (оценить) онытма (не забудь).

| | |
|---|---|
| Яхшы укый. | Яхшы укымый. |
| Дөрес укый. | Дөрес укымый. |
| Сәнгатьле укый. | Сәнгатьле укымый. |

**2.** Кызлар бергә нишлиләр?









**3.** Бу җөмләләр «Минем дустым» хикәясе эчтәлегенә туры киләме?

1. Айгөл һәм Айсылу авылда дуслаштылар. 2. Айгөл — авылда, Айсылу Казанда яши. 3. Айсылу — дүртенче сыйныфта, Айгөл бишенче сыйныфта укый. 4. Без заманча биюләр өйрәнәбез. 5. Айгөл өйдә әнисенә булышмый. 6. Кызлар бергә чаңгы шуалар, дәрес әзерлиләр.

**4.** Текстта кайсы җөмлә артык (лишнее)?

Без Айгөл белән авылда таныштык. Икебез дә җәйге каникулга авылга кайттык. Без авылда дуслаштык. Айгөл бүген Казаннан кайта.

**5.** Җөмләләрне киңәйтеп яз, тиз укырга өйрән.

Үрнәк: Без дуслаштык. Без авылда дуслаштык. Без Айгөл белән авылда дуслаштык. Без Айгөл белән җәйге каникулда авылда дуслаштык.

Җөмләләр: Без шуабыз. Ул булыша.

**6.** Иң матур хикәя сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә онытма.

| | |
|---|---|
| Дөрес сөйли.<br>Эчтәлекне (содержание) белә.<br>Сүзләрне дөрес әйтә. | Дөрес сөйләми.<br>Эчтәлекне белми.<br><br>Сүзләрне дөрес әйтми. |

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны куй, партадашың белән сөйләш.

1. — ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— ... ?
— Ул шәһәрдә яши.
— Сез бергә нишлисез?
— ... .

2. — Оля, әйдә түгәрәккә язылабыз.
— Кайсы түгәрәккә?

— ... .
— Син биергә яратасыңмы?
— ... .

**8.** Диалогны укы. Ничек уйлыйсың, Айдар белән Руслан дуслармы? Ни өчен алай (так) уйлыйсың?

— Алло, хәерле кич!
— Хәерле кич!
— Айдар, синме? Айдар, иртәгә (завтра) татар теле дәресенә яңа дәфтәр кирәк.
— Әйе, беләм, Руслан, иртәгә диктант язабыз.
— Айдар, синең яңа дәфтәрең бармы?
— Бар.
— Иртәгә миңа да бер дәфтәр алып кил әле.
— Яхшы, Руслан.
— Рәхмәт.

**9.** 7 нче күнегү диалогына охшаш диалог төзе, партадашың белән сөйләш.

## 97—98 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

| | |
|---|---|
| **чәчәк** — цветок | **чәчәкне** — цветок |
| **күлмәк** — платье | **күлмәкне** — платье |
| **чәчәгеңне** — свой цветок | |
| **күлмәгеңне** — свою рубашку, своё платье | |

**2.** Переведи.

1. У тебя есть платье? 2. Покажи мне своё платье. 3. У тебя есть сумка? 4. Покажи мне свою сумку.

**3.** Тәрҗемә ит:

китабыңны — твою книгу
дәфтәреңне — твою тетрадь
дәреслегеңне — ...
күлмәгеңне — ...
каләмеңне — ...
телефоныңны — ...
песиеңне — ...
этеңне — ...
аквариумыңны — ...
попугаеңны — ...

**4.** Попроси у друга его:

— карандаши;
— телефон;
— велосипед;
— ноутбук;
— книгу;
— бадминтон.

**5.** Текстны укы.

**Сылтау**

Ике дус кыз бар икән. Берсе икенчесенә әйткән:

— Дустым, синең ике песиең бар. Берсен миңа бир әле.

— Кайсысын бирим?

— Ак песиеңне бир.



— Юк, ак песине үзем бик яратам.

— Алайса кара песиеңне бир.

— Бик бирер идем, ләкин яхшы түгел. Миңа зурлар: «Үзең яратмаган әйберне бүләк итмә», — диделәр.

Гомәр Бәшировтан

**берсе икенчесенә** — одна другой
**берсен** — одного
**кайсысын** — которого, которую
**сылтау** — отговорка
**бирер идем** — отдала бы
**яратмаган әйбер** — нелюбимая вещь

**6.** Хикәяне рольләргә бүлеп укыгыз, сәхнәләштерегез.

**7.** Сорауларга җавап бир.

1. Кызның ничә песие бар?
2. Иптәш кызы нинди песине сорый?
3. Кыз нигә ак песине бирми?
4. Кыз нигә кара песине бирми?
5. Кыз нигә бер песине дә бирми?

**8.** Ничек уйлыйсың, хикәядәге кыз чын дусмы? Син аңа нинди киңәш (совет) бирер идең?

**9.** Әгәр хикәядәге кызлар чын дуслар булсалар, хикәя ничек үзгәрер иде? Хикәя төзеп кара.

**10.** Үзең язган хикәяне дустыңа сөйлә.

## 99—100 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**-чы/-че** кушымчалары яңа сүзләр ясый:
**бакча-чы** — садовод
**нефть-че** — нефтяник

**2.** Бирелгән сүзләрдән һөнәр исемнәре яса.

Балык, тимер, эш, китапханә.

**3.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән.

[дәрә́с], [дуслары́], [ты́ңлағы̆з], [сы̆йны̆фташла́р], [та$^{о}$бы̆шма́қ], [йәмлә́], [күңэл̄ә́].

**4. Исеңдә калдыр!**

**Если хочешь сказать о профессии своих родителей, то говори так:**
Минем әтием — төзүче.
Минем әнием — укытучы.

**5.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нишли?

    

**6.** **Исеңдә калдыр!**

**Если тебе хочется что-либо делать,**
**то говори так:**

ашый + сы килә, уйный + сы килә,
эчә + се килә, сөйли + се килә.

**7.** Хикәяне укы. Балаларга нигә күңелле булды?

## Алма

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Ул бик матур һәм хуш исле иде. Чулпанның алманы ашыйсы килде. Дәрес әзерләгәндә, Чулпан гел алмага карап утырды. Менә ул түзмәде, дуслары янына мәктәпкә китте.

— Дусларым, тыңлагыз әле! — диде Чулпан. — Хәзер мин сезгә бер табышмак әйтәм:

Түм-түгәрәк, тупмы әллә,
Бакчаларда юкмы әллә?
Балдан татлыдыр тәме.
Бу нәрсә?

— Алма! — дип кычкырдылар укучылар.

Балалар алманы бергә ашадылар. Аларга бик күңелле булды.



Идрис Туктардан

**хуш исле** — ароматный
**дәрес әзерләгәндә** — когда готовила уроки
**түм-түгәрәк** — круглый-круглый
**түзмәде** — не выдержала

**8.** Найди в тексте предложения о том, что:

— яблоко было красивым и ароматным;
— Чулпан пошла к одноклассникам;
— дети отгадали загадку;
— ребятам было хорошо.

**9.** Бу җөмләләр хикәя эчтәлегенә туры киләме?

1. Алма кызыл, ләкин хуш исле түгел иде.
2. Чулпанның алманы ашыйсы килде, ләкин ашамады.
3. Дәрес әзерләгәндә, Чулпан алманы ашады.
4. Чулпан дусларына алма алып барды.
5. Табышмак Чулпанның дусларына ошады.
6. Балалар табышмакның җавабын белмәделәр.
7. Балаларга бик күңелле, бик рәхәт булды.

**10.** Җөмләләрне укы. Сораулар куй.

Бабай алма бирде.
Бабай бер алма бирде.
Бабай Чулпанга бер алма бирде.
Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде.

**11.** 10 нчы күнегү үрнәгендә (по образцу) җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

Җ ө м л ә л ә р: Чулпан утырды. Чулпан китте.

**12.** Восстанови диалог, поговори с другом.

а) — … .
— Нинди алма бирим?

— Миңа кызыл алма кирәк.
— ... ?
— 2 килограмм үлчәгез әле.

ә) — Әнием, минем ашыйсым килә.
— ... ?
— Әйе, аш ашыйм.
— ... ?
— Чәй дә эчәсем килә.

## 101—102 нче дәресләр

**1.** Сиңа «Алма» хикәясенең кайсы өлеше ошады? Иң ошаган өлешен укы.

**2.** Ничек уйлыйсың, Чулпан сыйныфташлары белән дусмы? Дуслык нәрсәдә күренә? Чулпанга нинди бәя бирер идең, дәфтәреңә яз.

**3.** «Минем чын (настоящий) дустым» дигән темага кечкенә хикәя яз.

**4.** Үзең язган хикәяне сөйләргә өйрән.



**5.** Шигырьне укы. Бу шигырь нәрсә турында?

## Минем дуслар

Мин «Якты күл»дә
Булдым лагерьда,
Су буенда ул,
Бик матур җирдә.

Күбәйде тагын
Анда дусларым,
Алдым барысының
Мин адресларын:

Алты Рафаэль,
Унике Равил,
Уналты Ваня,
Унҗиде Шамил,

Нәсимә, Сима,
Сания, Соня,
Володя, Нина,
Верочка, Лена...

Кайткач, аларга
Яздым мин хатлар,
Истәлекләрне
Хәтердә саклап.

Баргач хатларым,
Алар шатланыр,
Һәммәсе миңа
Хат язып салыр:

Нәсимә, Сима,
Сания, Соня,
Володя, Нина,
Верочка, Лена...

Алты Рафаэль,
Унике Равил,
Уналты Ваня,
Унҗиде Шамил.

Бари Рәхмәт

**күбәйде** — стало больше
**истәлекләр** — воспоминания

Синең дусларың кемнәр? Сез бергә нишлисез?

## 103—104 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**Если хочешь сказать, что кто-то начинает что-либо делать, то говори так:**

**Алсу уйный башлады.** — Алсу начала играть.
**Катя эшли башлады.** — Катя начала работать.

**2. Җырлый башлады, елый башлады** фигыльләрен үрнәк буенча төрләндер.

Ү р н ә к:

| | |
|---|---|
| Мин укый башладым. | Без укый башладык. |
| Син укый башладың. | Сез укый башладыгыз. |
| Ул укый башлады. | Алар укый башладылар. |

**3.** Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзе.

1. Азат, башлады, быел, мәктәптә, яхшы, укый.
2. Ләйлә, уйный, иптәш, кызлары, башлады, белән.
3. Тиздән, җылы, яклардан, кайта, кошлар, башлый.

**4. Исеңә төшер!**



**кебек** — словно, как будто
**бик** — очень
**гел** — всегда
**соң** — после

**5.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Сап-сары, сары күбәләкләр кебек алар! 2. Кояш гел көлеп тора кебек тоелды. 3. Ул бик матур җырлый. 4. Ул гел безгә килә. 5. Кыштан соң яз килә.

**6.** Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | | |
|---|---|---|
| көлә | | китә |
| кайта | ? | бирде |
| күңелле | | елый |
| алды | | күңелсез |

**7.** Төрләнешне дәвам ит.

| Минем сары башмагым. | Минем сары башмакларым. |
|---|---|
| Синең … .<br>Аның … .<br>Безнең … .<br>Сезнең … .<br>Аларның … . | |

**8.** Бирелгән җөмләләрнең һәр сүзенә сорау куй.

1. Гөлшатның сары башмаклары бар. 2. Башмакларны әтисе Гөлшатка Мәскәүдән җибәрде. 3. Гөлшатның дус кызы Ләлә күршедә яши.

**9.** Рәсемгә кара һәм әйт: кызның нәрсәләре бар?



**10. Исеңә төшер!**

| **Хәзерге заман** | **Үткән заман** |
|---|---|
| кайт**а́** | кайт**ты́** |
| кил**ә́** | кил**де́** |

**11.** Поставь вместо точек подходящие по смыслу глаголы и запиши предложения в тетрадь.

а) Ләләнең әтисе (кайда?) фронтта.
Бүген Ләләнең әтисе (кайдан?) фронттан … .

ә) Гөлшат өйгә … .
Гөлшат өйдән … .
Гөлшат өйдә … .

## 105—106 нчы дәресләр

**1.** Хикәяне укы.

### Шыгырдавыклы башмаклар

Гөлшатның сары башмаклары бар. Сап-сары, сары күбәләкләр кебек алар! Башмаклар җырлый башладылар: «Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр!» Бик кадерле бүләк алар. Әтисе башмакларны Гөлшатка Мәскәүдән җибәрде. Гөлшатның әтисе — фронтта танкист.

Гөлшатның дус кызы Ләлә күршедә яши. Ләләнең дә әтисе фронтта. Тиздән әтисе кайта да Ләләгә дә шыгырдавыклы башмаклар алып бирә.

Менә Гөлшатның әтисе фронттан кайтты да инде. Әтисе белән өйгә бәхет кайтты. Өй эче яктырды, кояш та гел көлеп тора кебек тоелды.

Гөлшат, шатланып, Ләләләргә йөгерде.

— Әтием кайтты! Әтием кайтты! — дип кычкырып җибәрде ул.

Тик аңа беркем дә эндәшмәде. Ләлә белән әнисе икесе дә елыйлар иде. Ләлә Гөлшатка карады да:

— Хәзер минем сары башмакларым булмас инде, — диде.

Гөлшатка бик күңелсез булып китте.

**шыгырдавыклы башмаклар** — скрипучие башмачки
**яктырды** — стало светлее
**тоелды** — показалось
**булмас инде** — не будет
**беркем дә** — никто
**күңелсез булып китте** — стало грустно



**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

[баᵒшмақлáр], [шы̆ғы̆рдаwы̆қлы́], [қәдә̆рлә́], [күршә̆дә́], [бә́ркә̆м], [ә̆ндә́шмәдә̆].

**3.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Башмаклар җырлый башладылар: «Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр!» Башмаклар сары күбәләкләр кебек. Гөлшатның әтисе — фронтта танкист. Башмакларны әтисе Гөлшатка Мәскәүдән җибәрде. Ләләнең әтисе фронттан кайта да шыгырдавыклы башмаклар алып бирә.

**4.** Бу җөмләләр хикәя эчтәлегенә туры киләме?

1. Гөлшатның башмаклары сап-сары төстә.
2. Гөлшат башмакларны яратмый.
3. Гөлшатка башмакларны әнисе бүләк итте.
4. Гөлшатның әтисе фронтта, ул — танкист.
5. Гөлшатның әтисе фронттан кайтмады.
6. Ләләнең әтисе фронттан кайтты.
7. Гөлшат белән әнисе елыйлар.
8. Гөлшатка бик күңелсез булып китте.

**5.** Хикәядән үзеңә ошаган җөмләләрне табып укы.

**6.** Җөмләләрне укы, өстәлгән яңа сүзгә сорау куй.

1. Әтисе җибәрде.
   Башмакларны әтисе җибәрде.

Башмакларны әтисе Мәскәүдән җибәрде.

Башмакларны әтисе Гөлшатка Мәскәүдән җибәрде.

2. Әтисе кайта.

Әтисе фронттан кайта.

Ләләнең әтисе фронттан кайта.

Ләләнең әтисе фронттан кайта да башмаклар алып бирә.

**7.** Җөмләне 6 нчы күнегү үрнәгендә киңәйтеп яз.

Әтисе кайтты.

**8.** Сорауларга җавап бир.

1. Гөлшат башмакларны нигә ярата?
2. Башмакларны Гөлшатка кем ала?
3. Әтисе Гөлшатка башмакларны кайдан җибәрде?
4. Гөлшат нигә шатланды?
5. Гөлшат кемнәргә барды?
6. Гөлшатка нигә күңелсез булып китте?
7. Ләлә һәм әнисе нигә елыйлар?

**9.** Диалогларны хикәя эчтәлеге тәртибе буенча урнаштыр. Иптәшең белән сөйләшергә өйрән.

1. — Әни, мин Ләләләргә барыйм әле?
— Ярый, кызым, бар.
— Рәхмәт, әнием.

2. — Әнием, шыгырдавыклы башмакларны әтием кайдан җибәрде?
— Мәскәүдән, кызым. Сиңа ошыймы?
— Әйе, бик ошый. Мин аларны бик яратам.

3. — Әнием, әтием кайчан кайта?
— Тиздән, кызым, тиздән.

**10.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Гөлшат башмакларны бик ярата, чөнки … .
2. Гөлшат башмакларны бик ярата, шуңа күрә … .
3. Гөлшатка бик күңелле, рәхәт, чөнки … .
4. Гөлшатка бик күңелле, рәхәт, шуңа күрә … .
5. Ләлә елый, чөнки … .
6. Ләлә елый, шуңа күрә … .

**11.** Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрән.

## 107—108 нче дәресләр

**1.** Үрнәк буенча дәвам ит.

**Кайдан?** — Откуда?
**Кая кадәр?** — Докуда?

Үрнәк: Өйдән мәктәпкә кадәр. — От дома до школы.
Идән… түшәм… кадәр. — … .
Бакча… шәһәр… кадәр. — … .
Театр… тукталыш… кадәр. — … .
Мәктәп… тукталыш… кадәр. — … .
Тукталыш… өй… кадәр. — … .
Кибет… өй… кадәр. — … .

**2.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит.

Ләләнең дусты (иптәш кызы) — Алсу. — Подруга Ляли — Алсу.

Айдарның дусты — Саша. — ... .
Алсуның дусты — Оля. — ... .
Илнурның дусты — Коля. — ... .
Айнурның дусты — Камил. — ... .
Дамирның дусты — Сергей. — ... .

**3.** Хикәяне укы. Ләләнең дус кызлары сиңа ошыймы?

### Шыгырдавыклы башмаклар
(дәвамы)

Шул вакыт ишектән Ләләнең өч дусты килеп керде. Бер дусты зур курчак кочаклаган, бер дусты — кызыл туп, бер дусты матур чәчәкләр тоткан. Кызлар Ләлә янына килделәр.

— Бу туп идәннән түшәмгә кадәр сикерә. Мә, Ләлә, бу туп сиңа.

— Курчакның күзләре ачыла да йомыла. Ул мине бик ярата. Ул сине дә ярата. Курчак сиңа.

— Чәчәкләрне үзем алдым, — диде өченче кыз. Хуш исле чәчәкләрне Ләләгә сузды.

Тагын ишек ачылды. Бу юлы Гөлшатның әтисе керде.

— Ләлә, кызым! Мин сине иртәгә курчак театрына алып барам. Гөлшат та бара. Барасыңмы, Гөлшат?

Гөлшат бер сүз дә әйтмәде.

**ачыла** — открывается
**йомыла** — закрывается

**4.** Рәсемнәр кайсы җөмләләргә туры килә? Хикәядән табып укы.

  

**5.** Җөмләләрне укы. Сүз нинди предметлар турында бара?

1. Күзләре ачыла да йомыла. 2. Хуш исле. 3. Идәннән түшәмгә кадәр сикерә.

**6.** Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына кушымчалар өстәп укы.

1. Бер дусты зур  кочакла... . 2. Бер дусты кызыл  тот... . 3. Бер дусты матур  алып кил... .

**7.** Хикәяне рольләргә бүлеп укыгыз, сәхнәләштерегез.

**8.** Диалогларны укы һәм партадашың белән сөйләш.

а) — Катя, син Ләләгә нәрсә алып килдең?
— Зур курчак. Ә син?
— Мин туп алып килдем. Ул идәннән түшәмгә кадәр сикерә.

ә) — Кара әле, нинди матур курчак!
— Кем алып килде?
— Катя.
— Ә чәчәкләрне кем алып килде?
— Алсу.

**9.** Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрән.

## 109—110 нчы дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**Когда мы называем неопределённый предмет, то говорим:**
**нәрсәдер** — что-то;
**нидер** — что-то.
**А когда называем неопределённое лицо, то говорим:**
**кемдер** — кто-то.

**2.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Аларга кемдер килде.
2. Монда нәрсәдер бар.
3. Анда нәрсәдер шыгырдый.
4. Ул нәрсәдер эзли.
5. Аңа кемдер әйткән.
6. Кемдер ишек шакый.
7. Кемдер безгә кирә.

**3.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрән.

[чыгы́п кит̄ә́], [сŏрады́], [қуйды́], [баᵒшмақларны́], [йаᵒны́на́], [аᵒқы́л̄ы́м], [җиңә́л].

**4.** Хикәяне укы. Хикәянең бу өлешенә нинди исем куяр идең?

## Шыгырдавыклы башмаклар
(дәвамы)

Гөлшат тиз генә бүлмәдән чыгып китте. Ул нәрсәдер эзли башлады.

— Кызым, нәрсә эзлисең? — дип сорады әнисе.

— Берни дә түгел, — диде Гөлшат.

Үзе һаман нәрсәдер эзләде. Уенчыкларын берсен алды, берсен куйды...

Менә аның күзе сары башмакларга төште. Нинди матурлар! Ул башмакларны күкрәгенә кысты. Аннан соң әнисе янына килде.

— Әнием! Ләләгә кызлар чәчәкләр алып килделәр. Тагы курчак та, тагы туп та алып килделәр. Мин дә башмакларны бирәм, әнием, яме?

— Ярый, ярый, акыллым. Бик яхшы була.

Менә Гөлшат Ләләләргә керде.

— Ләлә! Мә башмакларны киеп кара! Сиңа ярыймы? — диде. Ул Ләләгә башмакларны бирде.

— Дускаем, мин сиңа башмакларны бүләк итәм. Ничек телисең, шулай ки.

Кинәт Гөлшатка бик җиңел, бик рәхәт булып китте.

Дәрҗия Аппаковадан



**күзе төште** — здесь: обратила внимание
**күкрәгенә кысты** — прижала к груди
**киеп кара** — примерь
**тагы** — ещё

**5.** Сүзләрнең антоним парларын билгелә.

| | | |
|---|---|---|
| бирә | | авыр |
| чыга | | сала |
| алды | ? | керә |
| җиңел | | китте |
| килде | | ала |
| кия | | куйды |

**6.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Гөлшат бүлмә... чыгып китте.
2. Гөлшат бүлмә... керде.
3. Гөлшат бүлмә... нәрсәдер эзләде.

**7.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп яз.

1. Гөлшат сары (нәрсәне?) ... бик яратты.
2. Гөлшатның күзе сары (нәрсәгә?) ... төште.
3. Мин сары (нәрсәне?) ... бүләк итәм.
4. Ләлә, мә сары (нәрсәне?) ... киеп кара.

**8.** Рәсемнәр урынына сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куй. Җөмләләрне укы.

1. Аның күз...  ... төш... . 2. Гөлшат  ... күкрәге... кыс... . 3. Әнием, кызлар Ләлә...  алып килделәр. 4. Мин  ... Ләлә... бирәм, яме, әнием?

**9.** План пунктларын хикәя тәртибендә урнаштыр.

1. Күзе сары башмакларга төште.
2. Гөлшат бүлмәдә нәрсәдер эзли башлады.
3. Гөлшат Ләләләргә керде.
4. Гөлшат әнисе белән киңәште.

**10.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар куй.

1. Гөлшат бүлмә... нәрсәдер эзли иде. 2. «Гөлшат, нәрсә эзли... ?» — дип сорады әни... . 3. Гөлшат... күзе сары башмаклар... төште. 4. Әнием, мин башмаклар... Ләлә... бирәм, яме? 5. Ләлә, мә башмаклар... киеп кара! 6. Мин сиңа башмаклар... бүләк итәм.

**11.** Хикәяне рольләргә бүлегез, сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирергә онытмагыз.

**12.** Сорауларга җавап бир.

1. Гөлшат бүлмәдә нәрсә эзләде?
2. Гөлшат башта нәрсә бүләк итәргә уйлады?
3. Гөлшат ни өчен сары башмакларны бүләк итәргә булды?
4. Гөлшатка ни өчен рәхәт, җиңел булып китте?

**13.** Ничек уйлыйсың, Гөлшат чын дусмы? Үз фикереңне яз.

## 111—112 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** По данным вопросам напиши рассказ о самом близком друге.

1. Синең дустың бармы?
2. Аның исеме ничек? Аңа ничә яшь?
3. Ул нинди?
4. Дустың кайда яши?
5. Ул кайда укый? Ничек укый?
6. Сез бергә нишлисез?

**2.** Узнай у друга:

— есть ли у него санки, лыжи, коньки;
— идёт ли он сегодня играть в хоккей;
— есть ли у них во дворе каток;
— идёт ли он вечером на танцевальный кружок.

**3.** Пригласи друга:

— сходить в магазин;
— вместе поиграть;
— записаться в спортивный кружок;
— кататься на лыжах;
— к себе домой.

**4.** Как скажешь, что:

— твой друг живёт в городе;
— он учится в четвёртом классе;
— он не жадный, а настоящий друг?

**5.** Нокталар урынына тиешле хәрефләр куеп яз.

Т...г...рәк, эшч...н, биш...ү, дусл...р, б...кчач..., дөр...с, таб...шм...к, тукт...лыш, к...дәр, уенч...к, уйныйб...з, дус...ым, с...йн...ф, б...л...к.

**6.** Сүзләрнең синоним парларын тап, алар белән җөмләләр төзе.

| | | |
|---|---|---|
| матур | | тату |
| зур | **?** | татлы |
| баллы | | олы |
| дус | | ямьле |

**7.** «Сылтау», «Алма», «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәяләрен исеңә төшер. Син кызлар турында нәрсәләр сөйли аласың?

**8.** Сүзләрнең антоним парларын тап, алар белән җөмләләр төзе.

| | | |
|---|---|---|
| юмарт | | кечкенә |
| матур | **?** | начар |
| зур | | саран |
| яхшы | | ямьсез |

# ДҮРТ АЯКЛЫ ДУСЛАРЫБЫЗ

## 113—114 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрнең тәрҗемәсен тап, дөрес әйтергә өйрән. Алар сиңа дүрт аяклы дусларыбыз турында сөйләргә ярдәм итәр.

[қŏйрóқ], [қŏлáқ], [ма$^{о}$ңғáй], [тәпи́], [йŏмшáқ], [кэ̆чкэ̆нә́], [ŏзóн], [хуҗá], [йа$^{о}$ратá], [а$^{о}$шатá].

**2.** Җөмләләр кайсы рәсемгә туры килә?

1. Аның койрыгы йомшак, колаклары кечкенә, күзләре яшел. Ул бик чиста. Үзе сөт ярата, тычкан тота.

2. Ул хуҗасын (хозяина) бик нык ярата. Үзе озын колаклы. Командалар үти, тәпиен (лапку) бирә.




**3.** Нокталар урынына кирәкле репликаларны куеп яз, диалогларны партадашың белән сөйләш.

а) — Коля, синең этең бармы?
— ... .
— Ул нинди токымнан?
— ... .

ә) — Айдар, син урамга чыгасыңмы?
— Әйе. Ә син чыгасыңмы?
— Мин Тузик белән чыгам. Ә син?
— ... .



**4.** Как изменились бы эти глаголы, если бы действия не происходили?

Эшли, сөйли, ярата, ошата, кайта, күрә, эзли, югалта, таба, китә.

**5.** Шигырьне укы. Малай яхшы эшләдеме?

**Дөньяда бер эт бар иде**



Дөньяда
Бер эт бар иде —
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Хуҗасы — шаян малай —
Этне ярата иде,
Аны ашата иде.
Ә бер мәлне, нигәдер,

Яратмый да башлады,
Ашатмый да башлады.
Илтеп шәһәр читенә
Адаштырды ул аны.
Шушы көнне үк төнлә
Эте керде төшенә:
— Ашыйсым килде,
Кайттым! — диде.
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.

Рөстәм Мингалим

**бар иде** — была
**шәһәр чите** — окраина города
**дөньяда** — в мире
**бер мәлне** — однажды
**тап** — пятно
**адаштырды** — оставил блуждать
**чак кына** — здесь: маленькое
**төш** — сон

**6.** Найди в стихотворении предложения, где говорится:

— о внешнем виде собаки;
— о положительном отношении мальчика к собаке;
— об изменении отношения мальчика к собаке.

**7.** Җөмләләрне шигырь тәртибендә урнаштыр. Эчтәлекне сөйләп кара.

1. Бер малайның кечкенә эте бар иде. 2. Аның маңгаенда кара тап бар иде. 3. Малай этне ярата, ашата иде. 4. Эт матур, кечкенә, йомшак, ак иде. 5. Малай этне шәһәр читенә илтте. 6. Бервакыт ул этне яратмый башлады, ашатмый да башлады. 7. Эт малайга: «Ашыйсым килә, кайттым!» — диде. 8. Малай этне төшендә күрде.

**8.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән.

## 115—116 нчы дәресләр

**1.** Шигырьне иң матур укучыга конкурс! Укыганга бәя бирергә онытма.

| | |
|---|---|
| Яхшы укый.<br>Авазларны дөрес әйтә.<br>Кычкырып укый.<br>Тиз укый. | Яхшы укымый.<br>Авазларны дөрес әйтми.<br>Кычкырып укымый.<br>Әкрен укый. |

**2.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Эт бик матур, ак төстә.
   Эт бик матур, кара төстә.
2. Этнең маңгаенда ак тап бар.
   Этнең маңгаенда кара тап бар.

3. Малай этне башта ярата иде.
   Малай этне башта яратмый иде.
4. Малай этне адаштырды.
   Малай этне алып кайтты.
5. Малай этне сагынды.
   Малай этне сагынмады.

**3.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Малай игътибарсыз, чөнки ... .
2. Малай этне сагына, ләкин ... .

**4.** Ничек уйлыйсың, малай этне сагынамы? Син шигырь эчтәлеген ничек дәвам итәр идең? Хикәя язып кара.

**5.** Допустим, у тебя потерялась собака. Какое объявление ты бы написал об этом?

**6.** Диалогларны партадашың белән сөйләш.

а) — Коля, синең нигә кәефең юк?
— Этем югалды.
— Кайчан?
— Кичә.
— Ничек югалды?
— Ул кечкенә әле. Мин өйгә кереп киттем. Ул берүзе калды.

ә) — Кызчык, нигә елыйсың?
— Мин адаштым.
— Нинди йортта торасың?

— Белмим.
— Йорт янында нәрсә бар?
— Кибет.
— Елама, хәзер йортны табабыз.

б) — Лена, нәрсә югалттың?
— Сумкам югалды.
— Кайда югалттың?
— Белмим.
— Игътибарсыз булырга ярамый. Әйдә эзлибез.
— Рәхмәт сиңа.

## 117—118 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**



**ашыйсым килә** — хочу есть
**уйныйсым килә** — хочу играть
**ятасым килә** — хочу лечь
**эчәсем килә** — хочу пить
**сикерәсем килә** — хочу прыгать

**2.** Бу җөмләләр кайсы рәсемнәргә туры килә?



Эт чаба. Эт утыра. Эт арт аягында тора. Эт ал аягында (на передних лапах) тора.

**3.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән.

### Кызыклы шәкерт

— Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син,
мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем
уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

— Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй,
зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!

Габдулла Тукай

**Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул** — Глупый пёс не разумеет — нет уж, сызмала учись!

**Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!** — Кости к старости твердеют, не согнёшься, как ни гнись!

**4.** Шигырьдән рәсемнәргә туры килгән юлларны укы.







**5. Исеңә төшер!**

Аффиксы **-мый/-ми** указывают на то, что действие не происходит:



укы-й — укы + **мый**
кил-ә — кил + **ми**
яз-а — яз + **мый**
бар-а — бар + **мый**

Мин уйна + **мый** + м
Син уйна + **мый** + сың
Ул уйна + **мый**

**6.** Җөмләләрне шигырь эчтәлеге тәртибе буенча (в последовательности содержания стихотворения) урнаштыр.

1. Акбай, кил әле, арт аягың белән тор. 2. Минем уйныйсым килә. 3. Минем сикерәсем килә. 4. Юк, кирәкми, мин өйрәнмим. 5. Мин әле кечкенә. 6. Зурайгач, эшкә өйрәнү авыр.

**7.** Сорауларга җавап бир.

1. Малай Акбайга нәрсә ди?
2. Акбайның өйрәнәсе киләме? Ул нәрсә ди?
3. Ничек уйлыйсың, эшләргә зур булгач кына өйрәнеп буламы? (Как ты думаешь, можно ли научиться работать, только встав взрослым?)

## 119—120 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

Аффиксы **-сыз/-сез** указывают на отсутствие чего-либо (кого-либо).

**дус белән** — с другом
**дуссыз** — без друга
**дәфтәр белән** — с тетрадью
**дәфтәрсез** — без тетради

**2.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Эта куртка без капюшона.
2. Я не пойду в театр без тебя.
3. Я не пойду на день рождения без подарка.
4. Ты мне дал ручку без пасты.

**3.** Сүзләрнең антонимнарын әйт.

матур — …
тиз — …
җылы — …
нечкә — …
ак — …

ап-ак — …
йомшак — …
яңа — …
кечкенә — …
озын — …

**4.** Табышмакның җавабын тап.

Нинди аучы коралсыз
Җәнлек аулый төн буе,
Аннан мыегын селкетеп
Йоклап ята көн буе?



**корал** — оружие
**мыегын селкетеп** — шевеля усами
**аулый** — охотится

**5.** Фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртеп яз, дөрес әйтергә өйрән. Җөмләләр төзе.

Ү р н ә к: килде — килмәде.

Ф и г ы л ь л ә р: күчеп килде, ява башлады, ачты, керде, тапты, утырды, бирде, йоклап китте.

**6. Исеңдә калдыр!**

**монда** — здесь
**тегендә** — там

**7.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Безнең урамда биш катлы йорт төзиләр.
2. Безнең подъездда өч кыз, өч малай торабыз.
3. Без гел бергә уйныйбыз.
4. Бүген урамда кояш юк, салкын җил исә.
5. Монда бик күңелле, бик рәхәт.
6. Тегендә яңа йорт салганнар.

**8.** Сүзләрнең тәрҗемәсен әйт, алар белән җөмләләр төзе.

Дус — ...; дуслар — ...; дуслаштылар — ... .

## 121—122 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укы.

### Ак песи

Төзүче абыйлар һәм апалар урамда бик матур биш катлы йорт төзиләр. Бу йортка беренче подъездга өч малай, өч кыз күчеп килде.

Алар бик тиз дуслаштылар. Кыш та, яз да, җәй дә гел бергә уйнадылар.

Менә көз җитте. Агач яфраклары саргайдылар. Яңгырлар ява башлады. Кошлар җылы якларга киттеләр.



Яңгырлы бер көндә Айдар урамга чыгып китте. Урамда кояш юк, салкын җил исә. Ул өйгә керде.

Айдар ишекне ачты. Кемдер нечкә тавыш белән:

— Мияу-у! — дип кычкырып куйды. Почмакта ап-ак песи утыра. Ул Айдарны күрде һәм тагын:

— Мияу-у! — дип куйды.

— Туңгансың бит, пескәй. Әйдә безгә керәбез, мин сиңа сөт белән күмәч бирәм, — диде Айдар.

Айдар аның алдына тәлинкә белән җылы сөт, йомшак күмәч куйды. Песи сөт эчә башлады. Аның тамагы туйды, һәм ул йоклап китте.

Менә Айдарның дуслары Галим, Рәзинә, Рәсимә, Тимер килделәр. Алар песине күрделәр һәм бик яраттылар.

— Ура! Ура! Безнең песиебез булды! — дип шатландылар.

Аннан соң бергә песигә исем уйладылар.

Газиз Мөхәммәтшин

**күчеп килде** — здесь: заселились
**тамак туйды** — насытился
**дуслаштылар** — подружились
**туңгансың** — ты замёрз
**күмәч** — булочка
**аннан соң** — потом

**2.** План пунктларын хикәя тәртибендә урнаштыр.

1. Менә көз җитте.
2. Төзүче абыйлар һәм апалар йорт төзиләр.
3. Айдар песине ашата.
4. Почмакта песи утыра.
5. Айдарның дуслары.

**3.** Хикәядән ике фигыльне сайлап ал (выбери). Төрләндер (проспрягай) һәм таблицага яз.

| | Хәзерге заман | Үткән заман |
|---|---|---|
| Мин<br>Син<br>Ул<br>Без<br>Сез<br>Алар | | |

**4.** Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә сораулар куй.

1. Айдар **песи алдына** тәлинкә белән җылы сөт, йомшак күмәч куйды.
2. Айдар песи алдына **тәлинкә белән** җылы сөт, йомшак күмәч куйды.
3. Айдар песи алдына тәлинкә белән җылы **сөт**, йомшак **күмәч** куйды.
4. Айдар песи алдына тәлинкә белән **җылы** сөт, **йомшак** күмәч куйды.

**5.** Хикәядән **кая? кайда?** сорауларына җавап булып килгән сүзләрне табып укы.

**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Төзүче апалар һәм абыйлар тугыз катлы йорт төзиләр.
   Төзүче апалар һәм абыйлар биш катлы йорт төзиләр.
2. Бу йортка икенче подъездга өч малай, ике кыз күчеп килде.

Бу йортка беренче подъездга өч малай, өч кыз күчеп килде.

3. Урамда кояш, җил юк, рәхәт иде.
   Урамда кояш юк, салкын җил исә.
4. Айдар өйгә кереп китте.
   Айдар өйгә кереп китмәде.
5. Почмакта кап-кара песи утыра иде.
   Почмакта ап-ак песи утыра иде.
6. Айдар песине өйгә алып керде.
   Айдар песине өйгә алып кермәде.
7. Айдар песигә сөт, ит, күмәч куйды.
   Айдар песигә сөт, күмәч куйды.
8. Песи йокламады.
   Песи йоклап китте.

**7.** Хикәяне сәнгатьле укырга өйрән.

## 123—124 нче дәресләр

**1.** «Ак песи» хикәясен рольләргә бүлеп укыгыз. Иң яхшы укучыны билгеләгез.

**2.** Бу рәсемнәр хикәянең кайсы җөмләләренә туры килә?






**3.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр. Хикәянең эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

1. Подъездга өч малай, өч кыз күчеп килде. 2. Көз килде. 3. Балалар бик тиз дуслаштылар. 4. Урамда салкын. 5. Песи туңган. 6. Айдар песигә җылы сөт, күмәч куйды. 7. Айдар урамга чыкты. 8. Почмакта бик матур, ап-ак песи утыра иде. 9. Балалар песи янына килделәр. 10. Алар шатландылар.

**4.** Хикәя эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.

**5.** «Дөньяда бер эт бар иде» шигырендәге һәм «Ак песи» хикәясендәге малайларга түбәндәге сыйфатларның кайсылары туры килә? Таблицага яз.

| Шигырьдәге малай | Хикәядәге малай |
|---|---|
| ... | ... |

Сыйфатлар: ярдәмчел, рәхимле, рәхимсез, игътибарсыз, игътибарлы, тәрбияле, тәрбиясез, яхшы, начар, саран, юмарт.

**6.** Восстанови диалоги и поговори с соседом по парте.

1. — ... .
— Сәлам! Айдар, син кайсы йортта торасың?
— 158 нче йортта.
— ... ?
— Биш катлы.
— ... ?
— Мин өченче катта торам.

2. — Коля, сезнең песиегез бармы?
— ... .
— Ул нинди?
— ... .
— ... ?
— Ул сөт эчә, балык ярата.

3. — ... ?
— Әйе, мин песине ашаттым.
— Нәрсә ашады?
— ... .

**7.** Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрән.

## 125—126 нчы дәресләр

**1.** Исеңә төшер һәм төрләнешне дәвам ит.

| **кая?** | **кайда?** | **кайдан?** |
|---|---|---|
| суга | суда | судан |
| басмага (на мостик) | ... | ... |
| урманга | ... | ... |
| елга буена | ... | ... |

**2.** Дәвам ит.

| **кая?** | **кайда?** | **кайдан?** |
|---|---|---|
| яр буена (к берегу) | яр буенда (у берега) | яр буеннан (от берега) |
| елга буена | ... | ... |
| ... | ... | ... |

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар өстә һәм тәрҗемә итеп яз.

1. Яр буе... бара.
   Яр буе... тора.
   Яр буе... кайта.

2. Елга... керде.
   Елга... чыкты.
   Елга... су керде.

**4.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстә. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзтезмәләргә сорау куй.

1. Без **су буе...** килеп җиттек. 2. **Су буе...** малайлар күп килде. 3. **Су буе...** кич сәгать биштә кайттык. 4. **Яр буе...** балыкчылар бик күп. 5. **Яр буе...** балыкчылар кайттылар. 6. Мин судан **яр буе...** чыктым.

**5.** Фигыльләрне тәрҗемә ит һәм дәфтәреңә яз.

Егылган, егылып төшкән, йөзә белми, кычкырып, чапкан, йөгерә башлаган.

**6.** Җөмләләрне киңәйтеп яз.

1. Су кердек. 2. Балык тоттык.

## 127—128 нче дәресләр

**1.** Сөйләргә өйрән.



Рабит Батулла — әкиятләр остасы. Ул балаларны бик ярата. «Сабантуй» газетасыннан, «Салават күпере», «Ялкын» журналларыннан аның әкиятләрен балалар бик яратып укыйлар.

**оста** — мастер

**2.** Бу сүзләрне онытма! Алар сиңа әкиятне аңларга ярдәм итәр.

**егылып төшкән** — упал
**батам** — тону
**коткарыгыз** — спасите
**качкан** — убежал
**ябышкан** — зацепился

**3. Исеңә төшер!**

**кычкыра башлаган** — начал кричать
**йөгерә башлаган** — начал бежать
**кача башлаган** — начал убегать (прятаться)

**4.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

[ты̆чқа́н], [йы̆ғы̆лы̆́п], [қо́тқары̆ғы̆з], [қы̆чқы̆рға́н], [қо̆йро̆ғо́н], [йаᵒбы̆шқа́н], [йы̆лға́], [туқта́маған], [қаᵒчарға́].

**5.** Әкиятне укы. Чикыл дөрес эшләгәнме?

## Чикыл белән Мырый

Тычкан баласы Чикыл басмадан чыга, ди. Кинәт ул суга егылган. Чикыл йөзә белми. Ул:

— Коткарыгыз, батам! — дип кычкыра башлаган.

Яр буеннан ата мәче Мырый килә икән.

— Мырый абый, коткар! — дип кычкырган Чикыл.

— Мин сине коткарам, әмма мин сине ашыйм бит, — дигән Мырый.

— Ярый, Мырый абый, коткар гына.

Мырый койрыгын елгага сузган. Чикыл аның койрыгына ябышкан да яр буена чыккан һәм йөгерә башлаган.



— Тукта! — дип кычкырган Мырый. — Тукта, дим! Мин сине ашыйм!

Әмма Чикыл туктамаган, качкан. Мәче күргәч качарга кирәк — моны барлык тычкан балалары да яхшы белә.

Рабит Батулладан

**басма** — мостик
**барлык** — все
**ярый** — ладно
**сузган** — протянул
**тукта** — постой

**6.** Әкияттән **нишләгән?** соравына җавап булган сүзләрне һәм сүзтезмәләрне тап һәм дәфтәреңә яз.

**7.** Найди в тексте предложения о том:

— что мышонок не умеет плавать;
— почему кот соглашается спасти мышонка;
— как кот спасает мышонка;
— что мышонок хитрый и умный.

**8.** Әкиятне сәнгатьле укырга өйрән.

## 129—131 нче дәресләр

**1.** Бу җөмләләрне кем әйтә?

— Коткарыгыз, батам! — диде … .
— Мин сине коткарам, әмма ашыйм, — диде … .
— Ярый, ярый, коткар гына, — диде … .
— Тукта! Мин сине ашыйм, — диде … .

**2.** Найди в сказке предложения, в которых говорится, что:

— по берегу идёт кот;
— мышонок вышел на берег;
— мышонок не остановился и убежал.

**3.** Бу раслаулар дөресме? Дөрес булмаса (если не верны), дөрес раслауны әйт.

1. Чикыл йөзә белә.
2. Чикыл басмадан яр буена егылып төшкән.
3. Яр буеннан ата мәче Мырый килгән.
4. Чикыл суда бата башлаган.
5. Мырый Чикылны коткармаган.
6. Мырый Чикылга койрыгын сузган.
7. Чикыл Мырыйның койрыгына ябышкан.
8. Чикыл туктаган, Мырыйны көткән.

**4.** Түбәндәге сорауларны кулланып, бирелгән җөмләдән сорау җөмләләр төзе.

Сораулар: кем? кемнең? нәрсәгә? нишләгән? кая?

Чикыл Мырыйның койрыгына ябышкан да яр буена чыккан.

**5.** Бу диалог әкиятнең кайсы өлешенә туры килә?

— Ябыш минем койрыкка.
— Ябыштым, ябыштым!
— Әйдә чык, мин койрыкны тартам.
— Мин чыктым, мин чыктым!

**6.** Нокталар урынына — кушымчалар, рәсемнәр урынына сүзләр куй.

1. — Коткарыгыз, батам! — дип кычкырган  .

2. — Мин сине коткарам, — дигән  .

3.  мәче... койрыгына ябыш... да су... чык... .

4. Тычкан  ... кач... .

**7.** Әкиятне рольләргә бүлеп укыгыз, сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирегез.

**8.** Сорауларга җавап бир.

1. Чикыл кайдан егылып төшкән?
2. Чикыл нигә бата башлаган?
3. Яр буеннан кем килгән?
4. Чикыл нәрсә дип кычкырган?
5. Мырый Чикылны ни өчен коткарырга уйлаган?
6. Мырый Чикылны ничек коткарган?
7. Чикыл ни өчен качкан?
8. Тычкан баласы Чикыл дөрес эшләгәнме?

**9.** Как скажешь о том, что:

— мальчик упал (на землю);
— ты не умеешь плавать;
— ты плаваешь хорошо;
— ты загораешь (на берегу);
— ты каждый вечер бегаешь;
— ты звал собаку, она не остановилась;
— твоя собака убежала?

**10.** Допустим, летом вы купаетесь в речке. Как позовёшь на помощь, если вдруг начнёшь тонуть?

**11.** Синең дүрт аяклы дусларың бармы? Аларның исеме ничек? Син аларны нәрсә белән сыйлыйсың? Алар нишләргә яраталар? Кечкенә хикәя төзе.



## 132—133 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Исеңә төшер: бу хикәяләрдә сүз кем турында бара? Син геройларга нинди бәя бирер идең? Таблицаны тутыр.

| Хикәя исеме | Төп герой | Төп геройга бәя |
|---|---|---|
| «Песнәк белән Әнисә» | ... | ... |
| «Чирик» | ... | ... |
| «Ак песи» | ... | ... |

Бәяләр: ярдәмчел, рәхимле, рәхимсез, игътибарлы, игътибарсыз, үкенә, үкенми, саран.

**2.** Сиңа «Ак песи» хикәясе ошадымы? Хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләп кара.

**3.** Укыган хикәяләрне исеңә төшер. Җөмләләрне дәвам ит.

1. Малай этне ашатмый башлады һәм ... .
2. Ак песинең тамагы туйды һәм ... .
3. Мин сине коткарам, әмма ... .
4. Әнисә песнәккә май бирде, шуңа күрә ... .

**4.** Сүзләрдән җөмләләр төзе.

1. Кара, маңгаенда, тап, бар.
2. Утыра, песи, иде, ап-ак, почмакта.
3. Ата, яр, мәче, буеннан, килә.

**5.** Сорауларга җавап бир һәм таблицага яз.

| Сораулар | Ак песи | Мырый |
|---|---|---|
| Ул нинди? | | |
| Нәрсә ярата? | | |
| Нишли? | | |

**6.** Нокталар урынына хәрефләр куеп күчереп яз.

П...с..., маэм...й, Ч...к...л, т...чк...н, й...мш...к, М...р...й.

**7.** Как скажешь о том, что:

— у тебя есть чёрная кошка с белым пятном на лбу;
— твоя кошка любит с тобой играть;
— ты угостишь кошку тёплым молоком;
— ты будешь скучать по кошке?

**8.** Узнай у друга:

— есть ли у него кошка, собака;
— гуляет ли он с собакой на улице;
— что ест, пьёт его кошка;
— что ест, пьёт его собака.

# ЯЗГЫ БӘЙРӘМНӘР

## 134—135 нче дәресләр

**1.** Яз билгеләрен (признаки) исеңә төшер. Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куеп укы, дәфтәргә яз. Сөйләргә өйрән.

Менә яз җитте.  җылыта.  эри. Елгада ... ага. Җылы яктан  кайта.

**2.** Спроси у друга:

— какие приметы весны он знает;
— нравится ли ему весна;
— знает ли он, какие птицы прилетают весной.

**3.** Син ел фасылларының билгеләрен беләсеңме? Рәсемнәргә карап, бер-берегезгә сораулар бирегез.






**4.** Сиңа кайсы ел фасыллары ошый, ни өчен?

1. Миңа яз ошый, чөнки ... .
2. Миңа көз ошый, чөнки ... .
3. Миңа җәй ошый, чөнки ... .
4. Миңа кыш ошый, чөнки ... .

**5.** Һәр ел фасылы үзенчә күңелле. Ә син һәр ел фасылында нәрсәләр эшлисең, ничек уйныйсың, ничек ял итәсең? Сөйлә.

**6.** Диалогка репликалар өстә, дустың белән сөйләшергә өйрән.

— Айдар, әйдә урамга чыгабыз.
— Ә көн нинди?
— ... .
— Кая барабыз?
— ... .

**7.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән.

**Яз**

Яз килде, кояш көлде,
Дөньяга нур бөркелде.
Уянды бар агачлар,
Куанды алмагачлар.

Резеда Вәлиева

**8.** Табышмакның җавабын тап.

Яз килсә — киенә.
Көз килсә — чишенә.

**9.** Яз турында сөйләргә өйрән. Сиңа яз ошыймы?

## 136—137 нче дәресләр

**1.** Дополни диалоги. Разыграй их с соседом по парте.

1. — Олег, син кемне бәйрәм белән котладың?
— ... .
— Ничек котладың?
— Открытка яздым, бүләк бирдем.
— Нинди бүләк?
— ... .

2. — Настя, сез бәйрәмгә нәрсә пешердегез?
— ... .
— Сезгә кунаклар килдеме?
— ... .
— Син әниеңә булыштыңмы?
— ... .

**2.** 8 нче Март бәйрәме белән әниеңә, әбиеңә, дусларыңа котлау яз.

**3.** Мәктәптә 8 нче Март бәйрәме ничек уза? Сөйләргә өйрән.

**4.** Ничек уйлыйсың, укучылар кемне котлыйлар?

Кадерле ... !

Сезне 8 нче Март бәйрәме белән котлыйбыз! Сезгә озын гомер, сәламәтлек, шатлык, эшегездә зур уңышлар телибез.

4 нче сыйныф укучылары



**5.** Диалогны үзара сөйләшегез.

— Катя, син кая барасың?
— Мәктәпкә.
— Мәктәпкә нигә барасың?
— Анда бүген бәйрәм була.
— Нинди бәйрәм була?
— 8 нче Март бәйрәме була.
— Бәйрәмдә нишлисез?
— Бәйрәмдә әниләрне, әбиләрне котлыйбыз, концерт куябыз.
— Син бәйрәмдә нишлисең?
— Бию.



**6.** Укы һәм әйт: кем матуррак?

Кечкенә кыз әнисенә үзенең курчагын күрсәтә.
— Әнием, әйт әле: кемнең кызы матуррак? Синең кызыңмы, минекеме?
— Ә син ничек уйлыйсың, кызым?
— Синең кызың матуррак, — дигән кыз.

**матуррак** — красивее

**7.** **Матуррак, тизрәк, күңеллерәк** дигән сүзләр белән җөмләләр төзе.

**8.** Диалогларны партадашың белән сөйләш.

1. — Катя, кая барасың?
— Мин адаштым.
— Адресны беләсеңме?
— Әйе. 165 нче йорт.
— Ул йорт кибет артында.

2. — Настя, нәрсә эшлисең?
— Мин китапны югалттым.
— Кайчан?
— Яңа гына.
— Менә бит. Телевизор артында.

## 138—140 нчы дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

[ә̆лә́к], [қа$^{о}$рға́], [бо̆тқа́], [йа$^{о}$рма́], [җы̆йға́н], [тоз], [уңға́н], [ба$^{о}$рғана̄́р], [пә̆шә̆ргәнә̄́р].

**2.** Бу ашамлыкларның исемнәрен искә төшер. Син аларны кибеттә ничек сорыйсың?



**3. Исеңә төшер!**

**Если говоришь о событиях, которых сам не видел, то используй глагол в такой форме:**

**Ул кайт-кан.** — Он вернулся (оказывается).
**Ул әйт-кән.** — Он сказал (оказывается).
**Ул йокла-ган.** — Он спал (оказывается).
**Ул пешер-гән.** — Он приготовил (оказывается).

**4.** Дөрес тәрҗемәне тап.

| | | |
|---|---|---|
| калдырып киткәннәр | ? | поели и ушли |
| алып киткәннәр | | оставили |
| кайтып киткәннәр | | ушли |
| ашап киткәннәр | | унесли |

**5.** Җөмләләрне укы. Астына сызылган (подчёркнутые) сүзләргә сораулар куй.

1. Балалар өйдән өйгә йөргәннәр.
2. Балалар су буена җыелганнар.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм җөмләләр төзе.



**7.** Текстны укы. Сиңа бу бәйрәмнәр ошыймы? Син нинди бәйрәмнәр беләсең?

### Карга боткасы

Яз көне бик матур бер бәйрәм була. Ул — Карга боткасы. Элек кешеләр язны каргалар алып килә дип уйлаганнар. Бәйрәм көнне балалар өйдән өйгә йөргәннәр, карга боткасы пешерергә ашамлыклар җыйганнар.

— Өйдәме түтәй?
Тизрәк бир күкәй.
Бирсәң безгә өч күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.
Май кирәк, ярма кирәк,
Карга туена бар да кирәк.
Шикәр кирәк, тоз кирәк,
Чыгар, түтәй, тизрәк.
Синең кебек уңган түтәй
Бу дөньяда бик сирәк.

Аннан соң балалар су буена җыелганнар. Алар анда (там) ботка пешергәннәр, чәй кайнатканнар, җырлар җырлаганнар, төрле уеннар уйнаганнар, бергәләшеп ботка ашаганнар.



Аннан соң балалар ботканы каргаларга калдырып киткәннәр.

— Рәхмәт, кошкайлар, безгә яз алып килдегез, — дигәннәр алар.

Каргалар, балалар кайтып киткәч: «Кар! Кар! Әйбәт дуслар бар-бар!» — дип рәхмәт әйткәннәр.

**карга боткасы** — воронья каша
**элек** — раньше
**уңган** — трудолюбивая
**дөньяда** — на свете
**ярма** — крупа
**күкәй** — яйцо
**сирәк** — редко
**түтәй** — тётушка

**8.** Карга боткасына балалар нәрсәләр җыйганнар? Нокталар урынына тиешле сүзләрне яз.

Балалар Карга боткасына ... / ... / ... җыйганнар.

**9.** Найди и выпиши из текста глаголы, выражающие действия, которые ты сам не видел.

**10.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куй. Бирелгән сүзләр белән 4—5 җөмлә төзе.

К...к...й, м...й, ...рма, т...ры, ...н, шик...р, т...з, җ...р, у...н, б...тка, к...рга, р...хмәт, к...шк...й.

**11.** Сорауларга җавап бир.

1. Элек яз көнендә нинди бәйрәмнәр булган?
2. Бәйрәм көнне балалар нишләгәннәр?
3. Алар нинди такмак әйткәннәр?
4. Су буенда балалар нишләгәннәр?
5. Балалар ботканы нәрсәләргә калдырып киткәннәр?
6. Каргалар нишләгәннәр?

**12.** «Карга боткасы» бәйрәме турында сөйләргә өйрән. Бәйрәмне сәхнәләштерегез.

**13.** Как скажешь о том, что:

— тебя пригласили на праздник;
— ты идёшь на праздник;
— с тобой идёт твой друг;
— мама сварила кашу, вскипятила чай?

**14.** Спроси у друга:

— знает ли он о празднике «Воронья каша»;
— пригласили ли его на праздник;
— идёт ли он на праздник;
— с кем он идёт;
— что приготовили сегодня в столовой.



## 141—142 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән. Тәрҗемә ит.

[ŏнóк̧], [кə̆чкə̆нə́], [к̧ы̆зчы́к̧], [йŏк̧лаға́н], [пə̆шə̆ргə́н], [са°вы́тса°ба́].

**2.** **Исеңдә калдыр!**

> **Парлы сүзләр** — Парные слова
>
> **Бала-чага, ата-ана, савыт-саба** — парлы сүзләр.

**3.** Җөмләләрне укы, парлы сүзләрне тап.

1. Урамда бала-чага тавышы ишетелә.
2. Без кием-салым кибетенә кердек.
3. Мин савыт-сабалар юдым.
4. Без көн-төн эшләдек.

**4.** Укы һәм әйт: икенче җөмләдә нәрсә үзгәргән?

1. Әбинең оныгы бар.
   Әбинең оныгы булган.

2. Кызчык йоклады.
   Кызчык йоклаган.

3. Кыз ипи пешерде.
   Кыз ипи пешергән.

**5.** Диалогларны укы. Дустың белән сөйләш.

1. — Кызым, савыт-сабаны кем юды?
— Белмим, әни. Мин юмадым.
— Ә кем юган?
— Сеңлем юган, ахры (наверное).

2. — Улым, машинаны кем юды?
— Мин юмадым, әти.
— Ә кем юган?
— Абый юган, ахры.

**6.** Хикәяне укы.

### Әбисе белән оныгы

Бер әбинең оныгы булган. Кечкенә кызчык йоклаган да йоклаган. Ә әбисе бөтен эшне үзе эшләгән. Ул ипи пешергән, өй җыештырган, савыт-саба юган, теккән.

Менә әбисе картайган. Ул мич башына менеп яткан. Хәзер әби йоклаган да йоклаган. Әбинең оныгы үскән. Ул ипи пешергән, өй җыештырган, савыт-саба юган, теккән.

Лев Толстойдан

**оные** — здесь: внучка
**картайган** — постарела
**теккән** — шила
**мич башына** — на печку
**үскән** — выросла

**7.** Найди в рассказе предложения о том, что делали бабушка и её внучка.

**8.** Хикәядән фигыльләрне тап, аларны таблицага яз.

| Настоящее время глагола | Прошедшее определённое время глагола | Прошедшее неопределённое время глагола |
|---|---|---|
| йоклый<br>...<br>...<br>... | йоклады<br>...<br>...<br>... | йоклаган<br>...<br>...<br>... |

**9.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Башта кыз йоклаган, әби эшләгән, чөнки ... .
2. Аннан соң кыз эшләгән, әби йоклаган, чөнки ... .

**10.** Как скажешь о том, что:

а) — ты убиралась дома;
— ты помыла посуду;
— ты шила;

б) — бабушка испекла хлеб;
— бабушка убиралась дома;
— бабушка спала?

**11.** 9 нчы күнегүне язмача эшлә.

## 143—144 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

> **Бир әле! (Бирче!)** — Дай, пожалуйста!
> **Миңа плеер бирегез әле! Миңа плеер бирегезче!** — Дайте мне, пожалуйста, плеер!

**2.** Рәсемнәр һәм нокталар урынына сүзләр куеп, дәфтәреңә яз.

Апа,  биреп тор … . Әнием, миңа  алыйк … . Алсу, дәфтәреңне күрсәт … . Олег,  биреп тор … . Әнием,  алыйк … .

**3.** Дустыңның үтенеченә (на просьбу) җавап бир.

Үрнәк: — Ипи ал әле.
— Хәзер алам.

— Гөлләргә су сипче!
— … .
— Ашарга әзерләргә булыш әле!
— … .
— Савыт-саба ю әле.
— … .

**4.** Бу сөйләшү сиңа ошыймы? Син аны ничек үзгәртер идең?

— Миңа карандашыңны бир әле.
— Юк, бирмим, ул берәү генә.
— Алайса бетергечеңне бир.
— Юк, үземә кирәк.

**5.** Әйтик, син иптәшеңнән кызыклы китап сорыйсың. Диалог төзе. Дәфтәреңә яз.

**6.** Спроси у подруги:

— убиралась ли она сегодня дома;
— помыла ли она посуду;
— есть ли у неё бабушка, дедушка;
— помогает ли она бабушке, дедушке.

**7.** Җөмләләрне укы, диалог төзе. Дустың белән сөйләш.

1. Миңа теге (тот) плеерны күрсәтегез әле. 2. Бар, ә нинди плеер кирәк? 3. Әйе, ул ничә сум тора? 4. Ул кыйммәт түгел, 1000 сум. 5. Сездә плеер бармы? 6. Менә бу кечкенә кара плеерныммы?

**8.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1. Покажите мне, пожалуйста, эту книгу. 2. Дайте мне, пожалуйста, хлеб. 3. Скажите, пожалуйста, сколько стоит молоко. 4. Мама, купи мне, пожалуйста, компьютер. 5. Папа, купи мне, пожалуйста, велосипед. 6. Оля, помоги мне, пожалуйста.

**9.** 8 нче күнегүдәге җөмләләр белән диалог төзе. Партадашың белән сөйләш.

## 145—146 нчы дәресләр

**1.** Шигырьне сәнгатьле итеп укы. Кайсы малай тәрбиялерәк?

### Рәхмәт

— Әхмәт, Әхмәт!
Тырысымны бирче рәтләп.
Әхмәт әйтә:
— Рәфгатькә әйт.
— Рәфгать, Рәфгать!
Тырысымны бирче рәтләп.
Рәфгать әйтә:
— Рәхмәткә әйт.
— Рәхмәт, Рәхмәт!
Тырысымны бирче рәтләп.
Бирде Рәхмәт шундук рәтләп.
— Рәхмәт, Рәхмәт!

Мәхмүт Газизов



**тырыс** — корзина
**шундук** — тут же
**бирче рәтләп** — почини, пожалуйста

**2.** Дөрес укы.

[тыр̆ыс̆ымны̆], [рәфғә́т], [әхмә́т], [рәхмә́т].

**3.** Сорауларга җавап бир.

1. **Рәхмәт** сүзе шигырьдә нинди мәгънәләр (значения) белдерә?
2. Рәфгать белән Әхмәт нинди малайлар?
3. Кызга тырысны кем рәтләп бирә?
4. Рәхмәткә нинди бәя бирергә була?

**4.** Бирелгән фигыльләрне үрнәк буенча үзгәрт. Алар ярдәмендә үтенеч (просьбу) белдер, җөмләләр төзе, дустыңа мөрәҗәгать ит (обратись).

Үрнәк: әйт — әйтче, әйт әле, әйтегезче.
Костя, әйт әле, математикадан өй эше бармы?

күтәр — ...
яса — ...
ярдәм ит — ...
үтүклә — ...
бир — ...
бар — ...
ал — ...
булыш — ...

**5.** Рәсемнәргә карап, үтенеч белдергән җөмләләр төзе.

Үрнәк: Айдар, китап бир әле.



**6.** Син бу әйтемне ничек аңлыйсың?

Яхшы сүз җанга рәхәт.

**7.** Тәрҗемә итеп яз.

Дай велосипед. Дай, пожалуйста, велосипед. Надо купить велосипед. Какой у тебя красивый велосипед! Я взял велосипед. У меня есть велосипед.

## 147—148 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**



Унбердән егермегә кадәр саннар кушма саннар була. Алар кушылып язылалар: **унбер**, **унике**, ... .

**2.** Саннарның язылышын истә калдыр. Алар белән җөмләләр төзе.

| Гади саннар | Кушма саннар |
|---|---|
| бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, егерме, йөз, илле, мең | унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез, унтугыз |

**3.** Ноктaлар урынына тиешле (нужные) саннарны куй.

1. Бер, ... , ... , дүрт, биш, ... , ... , сигез, ... , ун.
2. Унбер, ... , ... , ундүрт, ... , уналты, ... , унсигез, ... , ... .

**4.** Укы һәм әйт: кызлар ни өчен бер сүз дә әйтмиләр?

### Дүрт кыз

Әниләре:
— Зур сумка сатып алам.
Дүрт кыз да әйтә:
— Дүрт кечкенә сумка!
Әниләре әйтә:
— Зур яулык сатып алам!
Дүрт кыз да әйтә:
— Дүрт кечкенә яулык!
Әниләре әйтә:
— Щётка сатып алам, идән себерергә.
Кызлар бер сүз дә әйтмиләр...

Валентина Осеевадан

**5.** Сорауларга җавап бир.

1. Кызлар әниләреннән нәрсәләр сорыйлар?
2. Кызлар әдәпле сөйләшәләрме?
3. Ничек уйлыйсың, кызлар эш яраталармы?

**6.** Хикәяне сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирегез.

**7.** Син бу раслаулар белән килешәсеңме? Үз фикереңне белдер.

1. Кызлар эш яраталар.
2. Кызлар эш яратмыйлар.
3. Кызлар эшчән.
4. Кызлар ялкау.

5. Кызлар әниләренә ярдәм итәләр.
6. Кызлар әниләренә булышмыйлар.

**8.** Кызларга нинди бәя бирергә була? Сайлап ал.

Эшчән, тырыш, ялкау, шаян, әдәпле, эш яратмыйлар, тәрбиясез (невоспитанная), тыйнак (скромная).

**9.** Фикерне дәвам ит. Дәфтәреңә яз.

Миңа дүрт кыз да ошамый, чөнки ... .
Кызлар эшчән түгел, чөнки ... .

**10.** Әгәр сиңа сумка кирәк булса, ничек сорар идең? Үзеңә ошаган җөмләне сайлап ал.

1. Әни, миңа сумка ал!
2. Әни, миңа сумка ал әле.
3. Әни, миңа сумка кирәк, алыйк әле.
4. Әни, миңа сумка алчы.



**11.** Бергәләп көлик.

Әтисе, эштән кайткач, улыннан сорый:

— Сәлим, бүген әниеңә булыштыңмы?
— Юк. Сеңлем Мәрьямгә булыштым.
— Ничек?
— Икәү бер банка варенье ашап бетердек.

**12.** Син дүрт кыз турындагы хикәяне ничек үзгәртер идең? Язып кара.

## 149—150 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куй. Бу кайсы ел фасыллары?

1. Җирдә  күп. Елга өстендә ... ята.  су астында йоклыйлар.

2. Менә бөтен җиргә җылы, якты  елмайды. Көньяктан  кайттылар.  су өстенә чыктылар. Табигать уянды.

**2.** Яз аенда нинди бәйрәмнәр була? Берсе турында сөйлә.

**3.** Укытучыңны, дустыңны, әниеңне, әбиеңне 8 нче Март бәйрәме белән ничек котлыйсың?

**4.** Әйтик, бүген мәктәптә Әниләр бәйрәме, ди. Син әниләр турында нинди шигырьләр беләсең? Берсен сөйлә.

**5.** Нокталар урынына тиешле хәрефләр куеп, сүзләр белән җөмләләр төзе.

Р...хм...т, З...йн...п, ш...г...рь, й...м...рк..., ...чп...чмак, б...тка, са...ыт-с...ба.

**6.** Допустим, ты забыл дома ручку (тетрадь, линейку). Как ты попросишь их у друга?

**7.** Восстанови диалог. Поговори с соседом по парте.

1. — Әни, миңа сумка ал әле.
   — ... .
   — Әни, миңа зур сумка кирәкми.
   — ... ?
   — Әйе, кечкенә сумка кирәк.

2. — ... ?
   — Әйе, Оля эш ярата.
   — ... ?
   — Әйе, Марат та эш ярата.
   — ... ?
   — Алар әтигә, әнигә булышалар.

3. — ... ?
   — Юк, мин кибеткә бармыйм.
   — Кая барасың?
   — ... .

**8.** Что должен сказать Наиль, чтобы попросить Эльвиру:

— сходить в магазин;
— полить цветы;
— помыть полы?

# МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ

## 151—153 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәләрен исеңә төшер. Дәфтәреңә яз.

| | | |
|---|---|---|
| туган як | Ватан | милләт |
| туган ил | дәүләт | тел |

**2.** Шигырьне укы, ятла. Туган ил нәрсә ул?

### Туган ил

Туган ил ул — алтын арышлар,
Туган ил ул — зифа камышлар.
Туган ил ул — иркен болыннар,
Болыннарда нәни колыннар.
Туган ил ул — зәңгәр диңгезләр,
Туган туфрак, үскән нигезләр.
Туган илдә — барыбыз бертуган,
Бик кадерле безгә ул шуңа.
Туган ил ул була бер генә,
Туган илнең кадерен бел генә.

Зәкия Туфайлова

**3.** Текстны укы. Россия һәм Татарстан дәүләт символлары турында сөйләргә өйрән.

Татарстан Республикасы Россия дәүләтендә урнашкан. Россиянең дә, Татарстанның да үз дәүләт символлары бар. Россиянең Дәүләт флагы ак, зәңгәр, кызыл өлешләрдән тора. Дәүләт гербында ике башлы

бөркет сурәтләнгән. Татарстан гербында ак барс сурәтләнгән. Дәүләт флагында яшел, ак, кызыл төсләр бар.






**4.** Бу раслаулар белән килешәсеңме?

— Россиянең дәүләт символлары юк.
— Россиянең дәүләт символлары бар.
— Россиянең Дәүләт флагы ак, зәңгәр, кызыл өлешләрдән тора.
— Россиянең Дәүләт гербында ике башлы бөркет сурәтләнгән.
— Татарстанның Дәүләт гербында канатлы юлбарыс сурәтләнгән.
— Татарстанның Дәүләт флагы зәңгәр, яшел, ак төстәге өлешләрдән тора.

**5.** Шәһәр исемнәрен татарча әйт.

Казань
Зеленодольск
Чистополь
Альметьевск
Елабуга

Мензелинск
Заинск
Нижнекамск
Буинск
Набережные Челны

**6.** 3 нче күнегү текстының эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.

**7.** Кушымчаларны дөрес яз, схеманы куллан.

**Кая?**

Алёша — Чаллы, Алабуга, Зәй, Казан, Әлмәт, Мамадыш, Минзәлә **?** -га, -гә, -ка, -кә — китә.

**Кайда?**

Оля — Чаллы, Алабуга, Зәй, Казан, Әлмәт, Мамадыш, Минзәлә **?** -да, -дә, -та, -тә — яши.

**Кайдан?**

Әни — Чаллы, Алабуга, Зәй, Казан, Әлмәт, Мамадыш, Минзәлә **?** -дан, -дән, -тан, -тән, -нан — кайта.

**8.** Елгаларның татарча исемнәрен әйт. Җөмләләр төзе.

Волга — … ,
Белая — … ,
Ик — … ,
Вятка — … .

**9.** 5 нче күнегүдәге шәһәр исемнәре белән җөмләләр төзе.

Үрнәк: Мин Казанга барам.
Мин Казанда яшим.
Мин Казаннан кайтам.

**10.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куй, текстны укы.

Татарстанда … шәһәрләр, … авыллар бик … . Татарстан — … һәм … республика. Татарстанда татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, башкортлар, азәрбайҗаннар, мордвалар, белоруслар, украиннар һәм башка … яши. Бу милләтләр … һәм тату яшиләр.

Татарстанда дәүләт … : … теле һәм … теле.



## 154—156 нчы дәресләр

**1.** Бу сүзләрне онытма! Алар сиңа текстны аңларга ярдәм итәр.

**башкала** — столица
**мәчет** — мечеть
**манара** — башня (минарет)

**2.** Тәрҗемәне истә калдыр.

Казанский Кремль — Казан Кремле
Башня Сююмбике — Сөембикә манарасы
Мечеть Кул Шариф — Кол Шәриф мәчете

**3.** 2 нче күнегүдә бирелгән сүзтезмәләр белән җөмләләр уйла.

**4.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

[ба$^{о}$шкала́], [шәһә́р], [ко̆л шәри́ф], [сөйөмбикә́], [ма$^{о}$нара́], [ха$^{о}$лы́к], [бизәнү́ әйбә̆рләрә́].

**5.** Текстны укы, эчтәлеген сөйлә. Кайсы сүзләрне **анда** сүзе белән алмаштырырга мөмкин?



Мин Казанда еш булам. Казанда театрлар, музейлар, спорт корылмалары бик күп. 2013 нче елда Казанда җәйге Универсиада булды.

**спорт корылмалары** — спортивные сооружения

**6.** Текстны укы. Аңа нинди исем бирер идең?





Күптән түгел без Казанга экскурсиягә бардык. Казан — бик матур шәһәр. Без метрода йөрдек. Безгә Казан Кремле бик ошады. Анда Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы бар. Сөембикә манарасы җиде катлы. Манара очында алтын ай бар.

Татарстанның Милли музее Кремль янында урнашкан. Без музейда булдык. Безгә музей ошады.

**7.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар куй, күчереп яз.

1. Без Казан Кремле яны... булдык.
   Без Казан Кремле яны... килдек.
   Без Казан Кремле яны... киттек.
2. Без Сөембикә манарасы... булдык.
   Без Сөембикә манарасы... мендек.
   Без Сөембикә манарасы... төштек.

**8.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

Казан — бик матур шәһәр. Күптән түгел без Казанга экскурсиягә бардык.

Кремльдә Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы бар. Сөембикә манарасының очында алтын ай бар.

**9.** Диалогны сәхнәләштерегез.

— Марат, син җәй көне кая бардың?
— Казанга бардым.
— Кол Шәриф мәчетен күрдеңме?
— Әйе, без Кол Шәриф мәчетен күрдек.
— Ул кая урнашкан?
— Ул Кремльдә урнашкан.

**10.** Шигырьне укы. Туган тел ни өчен кадерле?

**Туган тел**

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Габдулла Тукай

## 157—158 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрне онытма! Алар сиңа текстны аңларга ярдәм итәр.

**башка** — бүтән
**очрашабыз** — встречаемся
**ерак** — далеко
**ерак түгел** — недалеко
**якын** — близко
**якын түгел** — неблизко

**2.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит.

Үрнәк: Казан Әлмәттән ерак.— Казань далеко от Альметьевска.

Зәй Әлмәттән ерак түгел. — Заинск недалеко от Альметьевска.

Арча Казанга якын. — Арск близко к Казани.

Мәскәү Казаннан ерак. — ... .

Ярославль Костромадан ерак түгел. — ... .

Зәй Чаллыга якын. — ... .

**3.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Шәһәр [шәһә́р], Баулы [баºулы́], Бөгелмә [бөгөлмә́], Әгерҗе [әгә̆рҗә́], ерак [йы̆ра́қ], якын [йаºқы́н], еш [йыш].

**4.** Текстны укы.

### Татарстан шәһәрләре

Татарстанның башкаласы — Казан. Яр Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, Чистай, Алабуга, Түбән Кама — Татарстанның зур шәһәрләре.

Мин — Бөгелмәдә, ә дустым Лена Әлмәттә яши. Без еш очрашабыз, чөнки Бөгелмә Әлмәттән ерак түгел. Без быел икәү җәй көне Казанга барабыз.

**5.** Бу шәһәрләр турында син нәрсәләр беләсең? Нокталар урынына тиешле сүзләр куй.

1. Әлмәт — ... шәһәр. Ул Казаннан ... . Анда ... яши.
2. Зәй — ... шәһәр. Ул Казаннан ... . Анда ... яши.

3. Алабуга — ... шәһәр. Ул Казаннан ... . Анда ... яши.

**6.** Таблицаны тутыр. Исемнәр белән җөмләләр төзе.

| Шәһәр исемнәре | Кая? | Кайда? | Кайдан? |
|---|---|---|---|
| Әлмәт | Әлмәткә | Әлмәттә | Әлмәттән |
| ... | ... | ... | ... |

**7.** Диалогларны укы. Иптәшең белән сөйләш.

1. — Азат, син җәй көне кая барасың?
— Казанга.
— Кем белән?
— Әни белән. Ә син кая барасың?
— Чистайга.
— Чистайда кемнәр яши?
— Минем әбием, бабам Чистайда яшиләр.

2. — Петя, әйт әле: Алабуга зур шәһәрме?
— Әйе, зур шәһәр. Алабугада университет бар.
— Алабуга Казаннан еракмы?
— Ерак.

**8.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куй.

Мин Казан шәһ...р...ндә ...шим. Ә дустым Азат Әлм...т шәһәр...ндә ...ши. Аның әтисе — нефтьч... . Азат җәй к...н... Каз...нга килә. Мин аны к...тәм.

**9.** «Татарстан Республикасы» дигән темага кечкенә хикәя төзе, сөйләргә өйрән.




## 159—160 нчы дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне яз.

Аг...йд...л, Н...кр...т, д...үл...т, шә...әр, таб...г...ть, тар...х, сәнг...ть, әдәби...т, әд...п, шаг...йрь, ш...гырь.

**2.** Как спросишь у друга о том:

— каких татарских и русских поэтов, писателей он знает;
— какие реки есть в Татарстане;
— какие исторические места есть в Татарстане?

**3.** Позови друга посетить музей. Убеди его в том, что там очень интересно.

**4.** Әйтемнәрне истә калдыр.

Туган илем — туган өем.
Туган илем — туган анам.

**5.** Спроси у друга:

— какие города в Татарстане он знает;
— знает ли он символику Татарстана;
— есть ли у них в городе музеи, театры;
— какие города России он знает;
— знает ли он символику России.

**6.** «Казан — Татарстанның башкаласы» дигән кичәдә син нәрсәләр сөйләр идең? Дәфтәреңә яз.

**7.** Кроссвордны чиш. Вертикаль баганадагы сүзне әйт.




1. Татарстандагы нефтьчеләр шәһәре.
2. «КАМАЗ» машиналары кайда чыга?
3. Атаклы татар шагыйре.
4. Татарстанның Дәүләт гербында сурәтләнгән хайван.
5. Вятка елгасының татарча исеме.
6. Казандагы тарихи манара.
7. Сәгать заводы кайсы шәһәрдә?
8. Татарстан башкаласы.
9. Татарстанның Дәүләт гимны музыкасы авторы.

**8.** Таблицаны тутыр.

| Татар язучылары, шагыйрьләре | Татар җырчылары | Татар рәссамнары |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

**9.** Как бы ты спросил, чтобы получить такие ответы?

— ... ?
— Без Татарстанда яшибез.
— ... ?
— Татарстанда татарлар, руслар, башкортлар һәм башка милләтләр яши.
— ... ?
— Алар дус һәм тату яшиләр.
— ... ?
— Без ике дәүләт телен дә өйрәнәбез.



# ЧӘЧӘКЛЕ ҖӘЙ, ЯМЬЛЕ ҖӘЙ

## 161—162 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укы. Салават күперендә нинди төсләр бар?

**Җәйге болында**

Кызыл, сары, зәңгәр, күк...
Бик күп төрле чәчәкләр
Сабантуйга җыелган.
Яңгыр үтте, җил тынды,
Күр салават күперен —
Бар да шуннан коелган:
Кызыл, сары, зәңгәр, күк...

Шәүкәт Галиев

**тынды** — здесь: утих
**салават күпере** — радуга
**коелган** — осыпались



**2.** Шигырьдә җәй ничек сурәтләнә? Шигырьдән җәй билгеләрен тап, аларны дәфтәреңә яз.

**3.** Шигырьне укы һәм әйт: җәй ни өчен күңелле, рәхәт?

**4.** Бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзе.

алан ис яңгыр салават күпере
басу төс җил кояш

**5.** «Җәйге табигать» темасына хикәя төзе. Бирелгән сүзтезмәләрдән файдалан.

Кояш кыздыра, кошлар сайрый, җиләкләр пешә, көннәр озын, төннәр кыска, су буе, оста балыкчы.

**6.** Восстанови диалоги и поговори с соседом по парте.

1. — ... ?
— Әйе, мин җәйне бик яратам.
— Ә ни өчен?
— ... .

2. — Дима, синең салават күперен күргәнең бармы?
— ... .
— Салават күперендә нинди төсләр бар?
— ... .

**7.** Спроси у друга:

— нравится ли ему лето;
— куда он поедет летом;

— идёт ли он в лес;
— собирает ли он ягоды.

**8.** 5 нче күнегүне язмача эшлә. Сөйләргә өйрән.

## 163—164 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укы. Урман ничек сөйләшә?

### Урман сөйләшә

Тыңлап торыгыз әнә:
Урман сөйләшә.
Үзең эндәшсәң аңа,
Ул да эндәшә.

«Син урманмы?» — дисәң,
«Урман... урман!» — ди.
«Җиләк уңганмы?» — дисәң,
«Уңган... уңган!» — ди.

Газиз Нәбиуллин



**уңган** — здесь: уродилась (ягода)

**2.** Шигырьдән урманның сөйләшүе турындагы җөмләләрне табып укы.

**3.** Әйтик, иптәшеңне урманга чакыргансың. Сез урманга кайчан бару, нәрсә алу турында сөйләшәсез. Диалог төзе.

**4.** Иң яхшы шигырь укучыга конкурс! Урман турындагы шигырьләрне укы. Укучыга бәя бирергә онытма. Бирелгән сүзләрне куллан.

| | |
|---|---|
| Сүзләрне дөрес әйтә.<br>Авазларны дөрес әйтә.<br>Сәнгатьле укый. | Сүзләрне дөрес әйтми.<br>Авазларны дөрес әйтми.<br>Сәнгатьле укымый. |

**5.** «Җәйге урман» дигән темага хикәя төзе.

**6.** Ошаса, шигырьне ятла.

## 165—166 нчы дәресләр

**1.** Шигырьне укы.

### Җиләктә

Җиләклектә
Җиләк күп.
Җиләклектә
Чиләк күп.

Һәр малайда
Бер чиләк!
Каян җыярга
Кирәк

Моның кадәрле
Җиләк?

Барыбер булмас
Тутырып,
Ашыйм гына
Утырып.

Рафис Корбан



**җиләклек** — ягодник
**моның кадәрле** — столько
**барыбер** — всё равно
**булмас тутырып** — не наполнить

**2.** Сорауларга җавап бир.

1. Җиләклектә нигә чиләк күп?
2. Уйла һәм әйт: җиләклектә ничә чиләк бар?
3. Малай нигә җиләк җыймый?

**3.** Җөмләләрне дәвам ит.

1. Малай җиләк җыймый, чөнки ... .
2. Малай җиләк җыймый, шуңа күрә ... .

**4.** Диалогларны укы. Иптәшең белән сөйләш.

1. — Костя, әйдә урманга барабыз.
— Ә нинди урманга?
— Күл янына. Анда бик матур урман бар.
— Еракмы?
— Юк, ерак түгел. Ярты километр.
— Мин риза. Сәгать ничәдә барабыз соң?
— Иртән сәгать җидедә.

2. — Лена, син бүген җиләккә барасыңмы?
— Юк, бүген бармыйм.
— Нигә?
— Бакчада эшем күп: чүп утыйм, су сибәм.
— Әйдә икәү эшлибез. Эш тизрәк бетәр.
— Рәхмәт, дустым. Аннан соң урманга барырбыз.

**5.** Табышмакның җавабын тап.

Башы бер, күзе унике.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: син сәгать ничәдә урманга барасың һәм ничәдә кайтасың?



**7.** Син бу җиләк-җимешләрне яратасыңмы? Алар кайда үсә?

Карлыган, балан, гөлҗимеш, кура җиләге, чия, җир җиләге, каен җиләге, миләш.



**8.** Бергәләп көлик.

Кечкенә Валяга әнисе әбисенә булышырга куша.

Үзе кайткач сорый:

— Әбиеңә булыштыңмы?

— Булыштым. Ул суган турады. Мин еладым.

**9.** Җиләк-җимешләр нинди?

карлыган<br>чия<br>миләш<br>кура җиләге<br>балан

?

ачы<br>баллы<br>татлы<br>тәмле

**10.** Диалогларга төшеп калган репликаларны яз.

1. — ... ?
— Юк, мин миләш яратмыйм.
— ... ?
— Чөнки ул ачы.
— ... ?
— Әйе, кура җиләге татлы, шуңа күрә аны яратам.

2. — ... ?
— Чия, карлыган, кура җиләге үсә.
— ... ?
— Әлбәттә, булышам. Су сибәм. Чүп утыйм.
— Ә син?
— ... .

**11.** Син татар халык ашлары исемнәрен онытмадыңмы? Рәсемнәргә кара, исемнәрен әйт. Син нәрсә яратасың?



## 167—168 нче дәресләр

**1.** Диалогны дәвам ит.

— Алсу, син җәй көне кая барасың?
— Авылга китәм.
— ... .

**2.** 1 нче күнегүдәге диалогка охшаш диалог төзе. Иптәшең белән сөйләшергә өйрән.

**3.** Пригласи друга к себе в гости. Скажи, где ты живёшь, в каком месяце лета ты будешь дома.

**4.** Спроси у друга:

— где он будет летом отдыхать;
— с кем он поедет;
— есть ли у него друзья в городе, в деревне;
— есть ли около них река, озеро;
— купается ли, загорает ли он летом.

**5.** Допустим, ты пишешь письмо другу. В письме ты сообщаешь о своих планах на лето. Как ты об этом напишешь?

**6.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән, тәрҗемәсен тап. Алар сиңа бик матур бер әкиятне аңларга ярдәм итәр.

[уты́н], [бы̆лты́р], [бы̆йы́л], [ағачны́], [йа°ры́йқ], [ба°лта́], [йа°ры̆ла́], [йа°ры́қ], [қы̆сты̆ра́], [қа°чқа́н], [қы̆сты́], [та°ба́р идэк].

**7.** Бу җөмләләр кайсы рәсемнәргә туры килә?

1. Бу — балта.
2. Ярыксыз бүрәнә.
3. Бүрәнәнең ярыгы бар.
4. Шүрәле бармагы.
5. Шүрәленең бармагы ярыкка кысылган.







**8.** Татар халык әкиятен укы.

## Шүрәле

Бер егет урманда утын кисә, ди. Аның янына бер Шүрәле килгән. Шүрәле егеткә:

— Син кем? Исемең ничек? — дигән.

Егет:

— Минем исемем Былтыр, — дигән.

Шүрәле егеткә:

— Әйдә кети-кети уйныйк әле, — дигән.

— Әйдә башта бу агачны ярыйк, аннан соң уйнарбыз, — дигән егет.

Егет балта белән бүрәнәгә чапкан, агач азрак ярылган. Шуннан соң егет Шүрәлегә әйткән:

— Мин хәзер агачтан балтамны алам, ә син бармагыңны ярыкка кыстырып торырсың, — дигән.

Шүрәле тагын риза булган. Ул бармагын ярыкка куйган, ә егет балтасын алган да качкан.

Шүрәле кычкыра башлаган:

— Бармагымны Былтыр кысты, Былтыр кысты!

Аның янына бүтән шүрәлеләр җыелган.

— Бармагыңны кем кысты? — дип сорыйлар икән.

— Былтыр кысты, — дип әйтә, ди.

Аңа әйткәннәр:

— Быел кысса, табар идек тә, былтыр кыскан бит. Былтырдан бирле ник кычкырмадың соң?

Шүрәле кысылган бармагы белән һаман да урманда йөри икән, ди.



**9.** Әкиятне сәхнәләштерегез.

## 169—170 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Җәй билгеләрен исеңә төшер. Җөмләләрне тулыландыр.

1. Җәй көне ... яңгыр ява, ... күпере чыга, ... балкый.
2. Җәен көннәр ... , төннәр ... була.
3. Урманнарны, аланнарны ... , ... , ... чәчәкләр бизи.

**2.** Син җәйне сагынып көтәсең. Җәйнең бер көнен ничек үткәрер идең? Кечкенә хикәя төзе.

**3.** Как скажешь о том, что ты летом:

— загораешь, купаешься;
— ходишь в лес, собираешь ягоды, грибы;
— едешь с родителями на дачу;
— помогаешь родителям на даче?



**4.** Кроссвордны чишсәң, милли бәйрәмне искә төшерерсең.

1. «Кыр» сүзенең синонимы.
2. «Җиләктә» шигырен кем язган?
3. «Дәү әни» сүзенең синонимы.
4. Кыргый хайван исеме. Ул бал ярата.
5. Анда җиләк үсә.
6. Биштән соң килгән сан.
7. Газиз Нәбиуллин шигырендә нәрсә сөйләшә?
8. Балалар кайсы ел фасылын бик яраталар?



# Сүзлек

## А

**абы́й** – старший брат, дядя

**ава́з** – звук

**авы́з** – рот

**авы́л** – деревня

**авы́р** – тяжело, тяжёлый; трудно, трудный

**авырта́** – болит

**авырый́й** – болеет

**ага́** – течёт

**ага́ч** – дерево

**агулы́** – ядовитый

**аз** – мало

**азы́к** – пища, корм

**ай** – месяц

**ак** – белый

**акбу́р** – мел

**акры́н** – медленно; медленный

**аку́ла** – акула

**акча́** – деньги

**акыллы́** – умный

**ала́** – берёт

**ала́н** – поляна

**ала́р** – они

**аларга́** – им

**аларны́** – их

**аларны́ң** – у них

**алдында́** – впереди

**алма́** – яблоко

**алмага́ч** – яблоня

**алта́у** – шестеро

**алты́н** – золото; золотой

**алырга́** – вычитать

**алъяпкы́ч** – фартук

**ана́** – мать

**анда́** – там

**анна́н соң** – потом

**аны́** – его, её

**аны́ң** – его, её; у него, у неё

**аңа́** – ему, ей;
к нему, к ней
**апа́** – старшая сестра,
тётя
**аркылы́** – через
**арттá** – позади, сзади
**арысла́н** – лев
**ас** – низ
**ат** – лошадь
**ата́** – отец
**атна́** – неделя
**ача́** – открывает
**аш** – суп
**а́ша** – ешь, кушай
**аша́** – через
**ашамлы́к** – продукт
**ашата́** – кормит
**а́ш-су** – кушанье
**ашханә́** – столовая
**ашы́й** – ест, кушает
**аю́** – медведь
**ая́з** – безоблачный
**ая́к** – нога

# Ә

**әбәклé уйны́й** – играет
в догонялки
**әби́** – бабушка
**әдәплé** – вежливый
**әзерли́** – готовит
**әйбә́т** – хорошо; хороший
**әйбéр** – вещь
**әйé** – да
**әйтә́** – говорит
**әкия́т** – сказка
**әкрéн** – медленно;
медленный
**ә́ле** – только, ещё
**әле** – -ка (скажи-ка)
**ә́нә** – вот
**әни́** – мама
**әрéм** – полынь
**әтә́ч** – петух
**әти́** – папа
**әфлису́н** – апельсин

# Б

**баба́й** – дедушка
**база́р** – рынок
**бай** – богач; богатый
**бака́** – лягушка
**бакча́** – сад
**бакчачы́** – садовник
**бал** – мёд
**бала́** – ребёнок
**бала́н** – калина
**баллы́** – сладкий
**балта́** – топор
**балы́к** – рыба
**балыкчы́** – рыбак
**бар I** – есть
**бар II** – иди
**бара́** – идёт
**барма́к** – палец
**ба́рыбер** – всё равно
**баса́** – встаёт
**басма́** – мостик
**баты́р** – герой, богатырь
**ба́у** – верёвка
**башкала́** – столица
**башлана́** – начинается
**башта́** – сначала, сперва
**бәби́** – младенец
**бәбкә́** – гусёнок; утёнок
**бәйрә́м** – праздник
**бәләкә́й** – маленький
**бәле́ш** – бэлиш
**бәрәңге́** – картофель
**бәхе́т** – счастье
**бәя́** – цена
**без** – мы
**безгә́** – нам, к нам
**безне́** – нас
**безне́ң** – наш
**белә́н** – с
**беле́м** – знание
**бер** – один
**бера́з** – немного
**бе́рвакыт** – однажды
**бергә́** – вместе, совместно
**беренче́** – первый

**бе́ркайчан** – никогда
**бе́ркем** – никто
**бе́рнинди** – никакой
**берсе́** – один из них
**бетә́** – заканчивается, завершается
**бетерге́ч** – стёрка
**бетте́** – закончилось, завершилось
**бие́к** – высоко; высокий
**бии́** – пляшет, танцует
**бик** – очень, весьма
**билге́ I** – отметка
**билге́ II** – признак предмета
**бирә́** – даёт
**бире́м** – задание
**бит I** – лицо
**бит II** – страница
**биш** – пять
**бишә́ү** – пятеро
**бишенче́** – пятый
**«биш»ле́** – пятёрка
**биялә́й** – варежка, варежки
**боз** – лёд
**боза́у** – телёнок
**бозлавы́к** – гололедица
**болы́н** – луг
**болы́т** – туча
**болытлы́** – облачно
**борча́к** – горох
**борчылу́** – беспокойство
**боры́н** – нос
**боры́ч** – перец
**ботка́** – каша
**бөе́к** – великий
**бөҗә́к** – насекомое
**бөре́** – почка
**бөте́н** – весь, целый
**бу** – это
**буенча́** – по
**була́** – бывает
**булыша́** – помогает
**бура́н** – буран, вьюга
**бүге́н** – сегодня

**бүлә́к** – подарок

**бүлә́к итә** – дарит

**бүлергә́** – делить

**бүлмә́** – комната

**бүре́** – волк

**бүре́к** – шапка

**бүтә́н** – другой

# В

**вак** – мелкий

**вакы́т** – время

**вата́** – разбивает

**Вата́н** – Родина

**ваты́к** – разбитый

**ватылга́н** – разбито

# Г

**гае́п** – вина

**гаилә́** – семья

**гафу́ ит(егез)** – извини(те)

**гоме́р** – жизнь

**гөбәдия́** – губадия

**гөл** – комнатный цветок

**гөлҗиме́ш** – шиповник

**гөмбә́** – гриб

# Д

**да (дә)** – тоже

**дару́** – лекарство

**даруханә́** – аптека

**дәре́с** – урок

**дәресле́к** – учебник

**дәфтә́р** – тетрадь

**дельфи́н** – дельфин

**ди** – говорит

**дөге́** – рис

**дөре́с** – правильно

**дуңгы́з** – свинья

**дус** – друг

**дуслы́к** – дружба

**дүрт** – четыре

**дүртә́ү** – четверо

**«дүрт»ле́** – четвёрка

**дүшә́мбе** – понедельник

# Е

**егермé** – двадцать

**егылá** – падает

**ел** – год

**елáн** – змея

**елгá** – река

**елмаý** – улыбается

**ел фасылы́** – время года

**елы́й** – плачет

**ерáк** – далеко

**еш** – часто

# Ж

**җавáп** – ответ

**җавáп бирә́** – отвечает

**җанвáр** – зверь

**җәéн, җә́й көне** – летом

**җәй** – лето

**җәнлéк** – зверь

**җидé** – семь

**җил** – ветер

**җилә́к** – ягода

**җилкә́** – плечо

**җимéш** – плод

**җимлéк** – кормушка для птиц

**җиңéл** – легко; лёгкий

**җир** – земля

**җитә́ I** – наступает

**җитә́ II** – хватает

**җитмéш** – семьдесят

**җомгá** – пятница

**җөмлә́** – предложение

**җыештырá** – убирает, прибирает

**җылы́** – тепло; тёплый

**җылытá** – греет

**җыр** – песня

**җырлы́й** – поёт

**җыя́** – собирает

# З

**замáнча** – современный

**зарарлы́** – вредный

**зәңгә́р** – синий, голубой

**зинһа́р** – пожалуйста

**зур** – большой

**зурла́р** – взрослые

# И

**игътиба́р** – внимание

**Иде́л** – Волга

**иҗе́к** – слог

**икә́н** – оказывается

**икә́ү** – вдвоём

**ике́** – два

**«ике»ле́** – двойка

**ил** – страна

**илле́** – пятьдесят

**ине́ш** – ручей

**иң** – самый

**ипи́** – хлеб

**иптә́ш** – товарищ

**иртә́** – утро

**иртәгә́** – завтра

**иртә́н** – утром

**иртәнге́ аш** – завтрак

**иртәрә́к** – пораньше

**ис** – запах

**исә́** – дует

**исә́нме(сез)** – здравствуй(те)

**и́скиткеч** – изумительный

**истәле́к** – воспоминание

**ит** – мясо

**итә́к** – юбка

**ите́к** – сапоги, сапог

**ише́к** – дверь

# Й

**йоклы́й** – спит

**йокы́** – сон

**йокыда́н тора́** – встаёт

**йомра́н** – суслик

**йомша́к** – мягко; мягкий

**йомырка́** – яйцо

**йон** – шерсть
**йорт** – дом
**йөгерә́** – бежит, бегает
**йөз** – сто
**йөзә́** – плывёт, плавает
**йөзе́м** – изюм
**йөрә́к** – сердце

# К

**каба́к** – тыква
**кабатлы́й** – повторяет
**кавы́н** – дыня
**кадерле́** – дорогой
**кадә́р** – до
**каз** – гусь
**казы́й** – копает
**ка́йбер** – некоторый
**ка́йда?** – где?
**кайма́к** – сметана
**кайна́р** – горячий
**ка́йсысы?** – который?
**кайта́** – возвращается
**ка́йчан?** – когда?
**кайчы́** – ножницы
**кана́т** – крыло
**каплы́й** – покрывает, закрывает
**капчы́к** – мешок
**кар** – снег
**кара́** – чёрный
**карабода́й** – гречка
**карбы́з** – арбуз
**кара́ карга́** – грач
**карлыга́н** – смородина
**карлыга́ч** – ласточка
**карт** – старый; старик
**карчы́к** – старуха
**каршылы́й** – встречает
**каршында́** – перед
**кары́й** – смотрит; ухаживает
**кат** – этаж
**каты́к** – катык
**кача́** – прячется
**кашы́к** – ложка

**ка́я?** – куда?
**ка́ян?** – откуда?
**котлы́й** – поздравляет
**кош** – птица
**коя́ш** – солнце
**кояшлы́** – солнечный
**кәбестә́** – капуста
**кәе́ф** – настроение
**кәҗә́** – коза
**кәрзи́н** – корзина
**кәшәкә́** – клюшка
**кебе́к** – как
**кем?** – кто?
**ке́мгә?** – кому?
**ке́мдер** – кто-то
**ке́мне?** – кого?
**ке́мнеке?** – чей?
**ке́мнең?** – кого? чей?
**кер I** – бельё
**кер II** – заходи, входи
**кер**ә́ – заходит, входит
**керергә́ мөмки́нме?** – можно войти?
**керпе́** – ёж
**кесә́л** – кисель
**кечкенә́** – маленький
**кеше́** – человек
**кибе́т** – магазин
**киенә́** – одевается
**кие́п карый́** – примеряет
**килә́** – приходит, идёт (сюда)
**килешә́** – идёт, подходит (об одежде)
**ки́нәт** – вдруг
**киң** – широкий
**киңә́ш** – совет
**кирә́к** – нужно, надо
**кисә́** – режет
**кита́п** – книга
**китә́** – уходит
**кич** – вечер
**кичә́** – вчера
**кич белән** – вечером
**кичке́ аш** – ужин
**кише́р** – морковь

**кия́** – надевает

**коела́** – осыпается

**коена́** – купается

**койры́к** – хвост

**кола́к** – ухо

**колы́н** – жеребёнок

**корт** – червь

**котла́у** – поздравление

**көз** – осень

**көймә́** – лодка

**көлә́** – смеётся

**көн** – день

**көндәле́к** – дневник

**көнде́з** – днём

**көндезге́ аш** – обед

**көрә́к** – лопата

**көрәшә́** – борется

**көтә́** – ждёт

**көчле́** – сильный

**куе́** – густо; густой

**кул** – рука

**кулъяулы́к** – носовой платок

**курка́** – боится

**курка́к** – трусливый

**кушарга́** – прибавить

**куя́** – ставит, кладёт

**куя́н** – заяц

**күбәлә́к** – бабочка

**күгәрче́н** – голубь

**күз** – глаз

**күзле́к** – очки

**күл** – озеро

**күлмә́к** – платье, рубашка

**күме́р** – уголь

**күнегү́** – упражнение

**күңелле́** – весело; весёлый

**күп** – много

**кү́пме?** – сколько?

**күрше́** – сосед

**кыз** – девочка

**кыздыра́** – печёт (солнце)

**кызы́к** – интересно; интересный

**кызы́л** – красный

**кыйба́т** – дорого; дорогой

**кыңгыра́у** – звонок

**кыр** – поле

**кыры́к** – сорок

**кыска́** – короткий

**кычытка́н** – крапива

**кыш** – зима

**кы́ш көне,**

**кышы́н** – зимой

**кыя́р** – огурец

# Л

**лалә́** – тюльпан

**лә́кин** – но, однако

# М

**май** – масло

**макты́й** – хвалит

**мату́р** – красиво; красивый

**мәка́ль** – пословица

**мәктә́п** – школа

**мәтрүшкә́** – душица

**ме́нә** – вот

**менә́** – поднимается

**мең** – тысяча

**милә́ш** – рябина

**миллә́т** – нация

**милли́** – национальный

**мин** – я

**мине́** – меня

**минеке́** – мой

**мине́м** – мой, у меня

**миңа́** – мне

**мич** – печь

**монда́** – здесь

**мөмки́н** – можно

**муе́н** – шея

# Н

**нача́р** – плохой

**нә́рсә?** – что?

**нә́рсәгә?** – чему?

**нә́рсәдер** – что-то

**нә́рсәнең?** – чего?

**нечкә́** – тонкий

**ни?** – что?

**ни́гә?** – зачем?

**ни́нди?** – какой?

**ни́чә?** – сколько?

**ни́чәнче?** – который?

**ни́чек?** – как?

**ни́ өчен?** – почему?

**ни́шләде?** – что сделал?

**нишлә́мәде?** – что не сделал?

**ни́шли?** – что делает?

**нокта́** – точка

# О

**ое́к** – чулки

**оекба́ш** – носок, носки

**оза́к** – долго

**озы́н** – длинный

**он** – мука

**оны́к** – внук, внучка

**оныта́** – забывает

**оста́** – мастер

**оча́** – летит

**очрашу́** – встреча

**очучы́** – лётчик

**ошы́й** – нравится

**оя́** – гнездо

# Ө

**өй** – дом

**өйрәнә́** – учится

**өлкә́н** – старший

**өрә́** – лает

**өре́к** – урюк

**өстә́л** – стол

**өсте́** – поверхность

**өстендә́** – на поверхности

**өтө́р** – запятая

**өч** – три

**өчә́ү** – втроём

**өче́н** – для

**өченче́** – третий

**«өч»ле́** – тройка

**өчпочма́к** – треугольник

# П

**пәнҗешә́мбе** – четверг

**пәрәмә́ч** – перемяч

**песи́** – кошка

**песнә́к** – синица

**печә́н** – сено

**пешерә́** – варит

**пеште́** – сварилось

**пилмә́н** – пельмени

**поши́** – лось

**пөхтә́** – аккуратно; аккуратный

**пыла́у** – плов

**пыча́к** – нож

**пычкы́** – пила

**пычра́к** – грязно; грязный

**пыяла́** – стекло; стеклянный

# Р

**рәсе́м** – рисунок

**рәсе́м ясы́й** – рисует

**рәхә́т** – приятно, отрадно

**рәхи́м ит(егез)!** – добро пожаловать!

**рәхмә́т** – спасибо

**риза́** – согласен, согласна

**рома́шка** – ромашка

**рөхсә́т** – разрешение

**ру́сча** – по-русски

# С

**сабы́н** – мыло
**савы́т-саба** – посуда
**сае́н** – каждый
**саеска́н** – сорока
**сай** – мелко; мелкий
**сайлы́й** – выбирает
**саклы́й** – охраняет, бережёт
**сала́** – кладёт; снимает
**салава́т күпере́** – радуга
**салкы́н** – холодно; холодный
**сан** – число
**санамы́ш** – считалка
**сандуга́ч** – соловей
**саны́й** – считает
**сара́н** – скупой
**сары́** – жёлтый
**сары́к** – овца
**сарымса́к** – чеснок
**сата́** – продаёт
**сатучы́** – продавец, продавщица
**саты́п ала́** – покупает
**са́у бул(ыгыз)** – до свидания
**сәга́ть** – часы
**сәла́м** – привет
**сәламәтле́к** – здоровье
**сәнә́к** – вилы
**сәхнә́** – сцена
**сез** – вы
**сезгә́** – вам, к вам
**сезне́** – вас
**сезне́ң** – ваш
**сеңе́л** – младшая сестра
**сибә́** – поливает
**сиге́з** – восемь
**сигезенче́** – восьмой
**сикерә́** – прыгает
**сиксә́н** – восемьдесят
**сине́** – тебя
**сине́ң** – твой, у тебя
**сиңа́** – тебе

**сишә́мбе** – вторник
**соклану́** – восхищение
**сора́у** – вопрос
**сора́у бирә́** – задаёт вопрос
**соң I** – поздно
**соң II** – после
**сөекле́** – любимый
**сөйли́** – рассказывает
**сөртә́** – вытирает
**сөт** – молоко
**су** – вода
**суга́н** – лук
**сузы́к ава́з** – гласный звук
**сүз** – слово
**сүзле́к** – словарь
**сые́р** – корова
**сыерчы́к** – скворец
**сызлы́й** – болит
**сызыклы́** – в линейку
**сыйны́ф җитәкчесе́** – классный руководитель

# Т

**таба́ (өйгә́ таба́)** – по направлению (к дому)
**табига́ть** – природа
**табы́н** – накрытый стол
**табышма́к** – загадка
**тавы́к** – курица
**такта́** – доска
**тама́** – капает
**тама́к** – горло
**тама́к тую́** – насытиться
**тамчы́** – капля
**тамы́р** – корень
**таны́ш** – знакомый
**тап** – пятно
**тапкырларга́** – умножить
**тар** – узкий
**тара́к** – расчёска
**тарата́** – раздаёт, разбрасывает
**тари́х** – история
**тарты́к ава́з** – согласный звук

**тата́р** – татарин; татарский

**тату́** – дружно

**та́у** – гора

**таш** – камень

**тәбәнә́к** – низкий

**тәлинкә́** – тарелка

**тәмле́** – вкусно; вкусный

**тәнәфе́с** – перемена

**тәрбияле́** – воспитанный

**тәрти́п** – порядок

**теге́** – тот

**тегүче́** – портной

**тел** – язык

**тели́м** – желаю

**теш** – зуб

**тие́н I** – белка

**тие́н II** – копейка

**тиз** – быстро

**тиздә́н** – скоро

**тик** – однако

**тимерая́к** – коньки

**тоз** – соль

**тозлы́** – солёный

**токма́ч** – лапша

**томшы́к** – клюв

**тора́ I** – встаёт, стоит

**тора́ II** – живёт

**тота́** – ловит

**төзәтә́** – исправляет

**төлке́** – лиса

**төн** – ночь

**төрле́** – разный

**төс** – цвет

**төсле́** – цветной

**төш** – сон

**төшә́** – спускается

**туга́н** – родной

**туга́н көн** – день рождения

**тугы́з** – девять

**туза́н** – пыль

**тук** – сыто; сытый

**тукра́н** – дятел

**тукталы́ш** – остановка

**туңа́** – замерзает, мёрзнет

**туп** – мяч

**түбәтә́й** – тюбетейка

**түгәрә́к** – круглый

**түли́** – платит

**тыңлы́й** – слушает

**тыры́с** – корзина

**тыры́ш** – старательный

## У

**уе́н** – игра

**уенчы́к** – игрушка

**уз** – проходи, входи

**уйны́й** – играет

**укучы́** – ученик

**укы́й** – читает; учится

**укыта́** – учит

**укытучы́** – учитель

**ул I** – он (она, оно)

**ул II** – сын

**ун** – десять

**уналты́** – шестнадцать

**унбе́р** – одиннадцать

**унби́ш** – пятнадцать

**ундү́рт** – четырнадцать

**унҗиде́** – семнадцать

**унике́** – двенадцать

**унө́ч** – тринадцать

**унсиге́з** – восемнадцать

**унтугы́з** – девятнадцать

**уңга́н** – умелый

**уңы́ш I** – успех, удача

**уңы́ш II** – урожай

**урма́н** – лес

**урнашка́н** – находится

**урынды́к** – стул

**уса́л** – злой

**ут** – свет, огонь

**уты́з** – тридцать

**утыра́** – сидит

**ураа́** – просыпается

# Ү

**үбә́** – целует

**үзе́** – сам (сама, само)

**үлә́** – умирает

**үлә́н** – трава

**үлчи́** – взвешивает

**үрдә́к** – утка

**үсә́** – растёт

**үстерә́** – выращивает

**үтә́** – проходит

**үтерде́** – убил

# Ф

**файда́** – польза

**файдалы́** – полезно; полезный

**фил** – слон

# Х

**хайва́н** – животное

**халы́к** – народ

**хат** – письмо

**хата́** – ошибка

**хаты́н** – жена

**хаты́н-кыз** – женщина

**хәерле́ көн!** – добрый день!

**хә́зер** – сейчас

**хәллә́р ни́чек?** – как дела?

**хәре́ф** – буква

**хикәя́** – рассказ

**хөрмәтле́** – уважаемый

**хуҗа́** – хозяин

**ху́ш(ыгыз)!** – прощай(те)!

**ху́ш килә́сез!** – добро пожаловать!

# Һ

**һәйкә́л** – памятник

**һәм** – и

**һәр** – каждый

**һә́ркем** – каждый (человек)

## Ч

**чаба́** – скачет

**чакыра́** – зовёт, приглашает

**чакыру́** – приглашение

**чалба́р** – брюки

**чана́** – сани

**чаңгы́** – лыжи

**чәкчә́к** – чак-чак

**чәнечке́** – вилка

**чәршә́мбе** – среда

**чәч** – волос

**чәчә́** – сеет

**чәчә́к** – цветок

**чәчә́к ата́** – цветёт

**чебе́н** – муха

**чеби́** – цыплёнок

**чикләве́к** – орех

**чир** – болезнь

**чирә́м** – трава

**члста́** – чисто; чистый

**чисталы́к** – чистота

**чия́** – вишня

**чөгендә́р** – свёкла

**чө́нки** – потому что

**чурта́н** – щука

**чүке́ч** – молоток

**чүлмә́к** – горшок

**чүпрә́к** – тряпка

**чыга́** – выходит

**чык** – выйди

**чынаяк** – чашка

**чыпчы́к** – воробей

**чыршы́** – ель

## Ш

**шагы́йрь** – поэт

**шакмаклы́** – в клетку

**шалка́н** – репа

**шалтырата́** – звонит

**шат** – рад

**шатлана́** – радуется

**шая́н** – весёлый

**шәһә́р** – город

**шигы́рь** – стихотворение

**шикә́р** – сахар

**шимбә́** – суббота

**шуа́** – катается

**шугала́к** – каток

**шук** – шустрый

**шул** – тот

**шуңа́ күрә** – поэтому

**шушы́** – это

## Э

**эз** – след

**эзли́** – ищет

**элә́** – вешает

**элге́ч** – вешалка

**эле́к** – давно

**энә́** – игла

**эне́** – младший брат

**энҗе́ чәчә́к** – ландыш

**эре́** – крупный

**эри́** – тает

**эссе́** – жарко; жаркий

**эт** – собака

**эчә́** – пьёт

**эчәсе́ килә́** – хочется пить

**эчендә́** – внутри

**эш** – работа

**эшли́** – работает

**эшче́** – рабочий

## Ю

**ю** – мой

**юа́** – моет

**югалта́** – теряет

**юк** – нет

**юл** – дорога

**юма́рт** – щедрый

**юына́** – умывается

## Я

**ява́** – идёт (снег, дождь)

**явы́з** – злой

**явымсы́з** – без осадков

**яз** – весна

**яза́** – пишет
**я́з көне, язы́н** – весной
**як (туга́н як)** – сторона (родная сторона)
**якты́** – светлый
**якы́н** – близко; близкий
**я́к-якка** – по сторонам
**ялгы́ш** – ошибочно
**я́л итә** – отдыхает
**ялка́у** – ленивый
**я́л көне** – выходной
**я́ме** – ладно
**ямьле́** – прекрасно; прекрасный
**ямьсе́з** – некрасиво; некрасивый
**яна́** – горит
**янында́** – возле, около
**яңа́** – новый
**яңгы́р** – дождь
**яр** – берег
**яра́мый** – нельзя
**ярата́** – любит
**ярдә́м** – помощь
**ярма́** – крупа
**ярыш́** – соревнование
**ясы́й** – делает, рисует
**ята́** – лежит
**ятлы́й** – учит наизусть
**яулы́к** – платок
**яфра́к** – лист
**яфра́к яра́** – распускает листья
**яхшы́** – хорошо; хороший
**яше́л** – зелёный
**яшелчә́** – овощ
**яши́** – живёт
**яшь I** – год
**яшь II** – молодой
**яшь III** – слеза
**яшьлә́р** – молодёжь

# Эчтәлек

**Минем дусларым**

91—112 нче дәресләр ........................... 4

**Дүрт аяклы дусларыбыз**

113—133 нче дәресләр ......................... 36

**Язгы бәйрәмнәр**

134—150 нче дәресләр ......................... 60

**Минем туган илем**

151—160 нчы дәресләр ......................... 81

**Чәчәкле җәй, ямьле җәй**

161—170 нче дәресләр ......................... 93

**Сүзлек** .................................................. 105

Учебное издание
Серия «Күңелле татар теле»

Хайдарова Роза Закиевна
Ахметзянова Гульназ Магсумзяновна
Гиниятуллина Лейсан Адиповна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**4 класс**

Учебник для образовательных организаций начального общего образования

В двух частях

Часть 2

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина*
Научный консультант *Ф.А. Ганиев*
Руководитель проекта *М.Ф. Ганиев*
Художественный редактор *С.В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д.И. Бариев*
Вёрстка *Е.Б. Шараповой*
Координатор проекта *А.М. Ганиев*
Технический руководитель *М.Р. Башаров*
Редакторы *А.А. Башарова, Ф.Ш. Ахметзянова*
Художники *А.Р. Ромашова, Н.К. Авдеева, М.М. Нигмедзянова*
Руководитель административной группы *А.Н. Зайнуллина*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 20.04.2014. Формат 84x108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная». Печать офсетная. Уч.-изд. л. 8. Тираж 27000 экз. Заказ №2025.

Издательство «Татармультфильм».
420034, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных издательством «Татармультфильм» материалов в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте **www.balarf.ru (www.бала.рф).**





ФГОС

**Школьный учебник**

серия

# «Күңелле татар теле»



9 785906 508027

издательство

«Татармультфильм»